

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# «БЕЗ ПЛИНДӘ ЯТАМЫЗ ЧИТЛЕКТӘГЕ КОШ КЕБЕК...»

«МИЛЛИ КИТАП»

**ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ**

# «БЕЗ ПЛИНДӘ ЯТАМЫЗ ЧИТЛЕКТӘГЕ КОШ КЕБЕК...»

## БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫ БӘЕТЛӘРЕ

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2014

УДК 902/904 + 821.512.145
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)
Б 35

*Төзүчесе, басмага әзерләүче*
*һәм мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
Раиф Мәрданов

Б 35 **«Без плиндә ятамыз читлектәге кош кебек...»**: Беренче бөтендөнья сугышы бәетләре / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2014. – 119 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 13 нче китап).

ISBN 978-5-88473-070-0

Китапта татар солдаты Мифтахетдин Галимов дәфтәрендә язылган бәетләр нәшер ителә.

Беренче бөтендөнья сугышы турындагы бәетләрнең дистәләгән вариантлары бар һәм аларның төрле җыентыкларда, вакытлы матбугат битләрендә басылып чыккан текстлары шактый. Ләкин бу китапта тәкъдим ителгән «Сугыш әхваленнән», «Ятимнәр бәете», «Плиннәрнең бәете» һәм «Сугыш бәете» текстларының моңарчы чыкканы юк иде.

Кереш мәкаләдә әлеге сугышка багышланган бәетләрнең 1914–1917 елларда ук аерым китаплар булып чыккан һәм аннан соңгы чорда нәшер ителгәннәренә, кульязма хәлендә саклана торганнарына гомуми күзәтү ясала. Шунда ук әсирлек темасына язылган мәкаләләр турында мәгълүмат бирелә.

ISBN 978-5-88473-070-0

УДК 902/904 + 821.512.145
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)

© Мәрданов Р.Ф., 2014
© «Милли китап» нәшрияты, 2014

## «СУГЫШТА ВӘЙРАН БУЛА ГАЗИЗ БАШЛАР...»

Кешелек тарихындагы иң канкойгыч дәһшәтләрнең берсе булган Беренче бөтендөнья сугышы башлануга быел 100 ел тула. Әлеге сугышта рус армиясе составында татар солдатлары да бик күп катнашкан. Татарлар аны Герман сугышы һәм Яурупа сугышы дип атаганнар. Шул чорда нәшер ителгән татар газета-журналларында сугыш вакыйгалары киң яктыртылган. Татар солдатларының көндәлекләре, җырлар һәм бәетләр язылган куен дәфтәрләре шул елларның истәлекләре булып безнең көннәргәчә сакланган. Татар сугышчыларының бер өлеше сугыш кырлары, окоп җәфалары һәм әсирлек газаплары кебек катлаулы шартларны исән кичеп, үзләренең моң-сагышлары, хыял һәм өметләре теркәлгән, күз яшьләре тамган һәм җан җылысы сеңгән дәфтәрләрен туган якларга алып кайтканнар. Андый дәфтәрләрне кадерләп саклаганнар, күп еллар узгач та укып моңланганнар.

Беренче бөтендөнья сугышына багышлап язылган күп санлы бәетләр фронтның алгы сызыгындагы солдатлар тарафыннан иҗат ителгән. Ул чордагы вакыйгалар турында язылган бәетләрнең күптөрле вариантлары бар. Герман сугышы башланган 1914 елда ук аның турындагы бәетләр китап итеп бастырылган. Мәсәлән, «Яурупа сугышы бәете» дип исемләнгән китапта «Дустлар илә бәхилләшү» исемендәге бәет һәм китапның ахырында «Бер солдатның хатынына җибәргән хаты» һәм «Солдатның ата-анасына мәктүб» текстлары туплап бирелгән. Хатлар 1914 елның октябрендә язылган итеп күрсәтелгән[1]. Китаптагы шактый күтәренке патриотик рухта язылган текстлар рус армиясенең сугыш башын-

[1] Яурупа сугышы бәете. – Казан: Кәримевләр матбагасы, 1914. – 16 б.

дагы уңышларына бәйле булганлыгы аңлашыла. Яшәү һәм үлем, бәхилләшү, ятимлек кебек мәсьәләләр искә алынса да, китапта

«Хисабы юк күп руслар арасында,
Хисабы аз, гайрәте күп татарбыз без!»

– дигән баһадиранә юллар да бар. Хәер, көчле дошманга каршы башланган зур сугыш вакытының цензурасы төшенке рухтагы әсәрләрне бастыртмас та иде. Бу китап кабат-кабат нәшер ителеп, 1917 елда аның дүртенче басмасы дөнья күргән. Яңа басмаларында текстагы кайбер сүзләре үзгәртелгән һәм ахырдагы хатлар да 1915 елның октябре белән даталанган. Бу китапның 1915 елда чыккан бер нөсхәсен шул сугышта әсирлеккә төшкән Хәбибрахман Яруллин (Сарман районында яшәгән) үзе белән саклап йөртеп алып кайткан булуы турында Дамир Гарифуллин язган мәгълүмат газетада басылган иде[2].

Беренче бөтендөнья сугышының икенче елында берничә төрле бәет китабы басылган. Мәсәлән, «Гъ. С.» имзасы астында дөнья күргән «Сугыш бәете» исемле китап «Бер солдатның 15 мәртәбә сугышта булып, 16 нчысында каты җәрәхәтләнгәне, 16 сугышта күргән хәлләре һәм лазаретта ятып моңлайган сүзләре» дип тәкъдим ителгән[3]. Бәетнең эчтәлеге, тулаем алганда, күтәренке һәм патриотик рухта.

Тагын бер бәет Мөхәммәдхатыйп бине Габделлатыйф әл-Кормаши әсәре буларак, «Яурупа сугышы хәлләренең бәете» исеме белән нәшер ителгән[4]. Бу китапның титул битендә әсәрнең «Грозный промысласында[5] 1914 нче ел 27 нче декабрьдә» язылган булуы искәртелгән. Шунда ук «Австрия-Германия сугышында бик күп кәррә булып, соңра мәҗрух булып кайтып, сугышны үз күзе илән күреп тасвир кылган мөселман солдаты аркылы тәртип кылынган бәетләрдер» дигән аңлатма-аннотация дә бирелгән. Бәетнең башында сугыш хәбәре килү һәм илдән-туганнар-

---

[2] Гарифуллин Д. Мөхтәрәм татар // Ватаным Татарстан. – 1993. – 26 март.

[3] Гъ. С. Сугыш бәете. – Казан: нашире – Шәмсетдин Хөсәенев вәрәсәсе; Домбровский матбагасы, 1915. – 16 б.

[4] Әл-Кормаши Мөхәммәдхатыйп. Яурупа сугышы хәлләренең бәете. – Казан: Кәримевләр матбагасы, 1915. – 16 б.

[5] *Грозный промысласы* – монда Кавказда нефть чыгаруда эшләү күздә тотылган.

дан аерылу, хушлашуның мәхшәргә тиң хәсрәте, яу кырындагы дәһшәтләр, сугыш вакыйгалары, толлар-ятимнәр тәфсилле тасвирланган. Шулай ук дошманны җиңү дәрте, рух күтәренкелеге дә бар. Китап булып басылган бу бәет тексты барлыгы 249 икеюллыкны тәшкил итә. Ул ел саен нәшер ителеп торган һәм аның соңгы басмасы 1917 елда дөнья күргән. Әлеге басма китапны күчереп тә язганнар. Совет чорында шушы китаптагы бәет текстының аерым өлешләре, төп чыганагына ишарә ителмичә (дөресе – аның булганлыгын белмәүдән), төрле басмаларда дөнья күргән иде[6]. Шулардан «Казан утлары» журналында Дамир Гарифуллин бастырган өлешен Сарман районындагы Яхшыбай авылының Садрислам Сагындыков әйтеп яздырган булган[7]. Әлеге бәетнең кыскартылган һәм бераз үзгәртелгән, яртысыннан кимрәк – 95 икеюллык күләмендәге өлеше 1983 елда чыккан бәетләр җыентыгында дөнья күрде[8]. Бу китапка ул Татарстанның Норлат станциясендә яшәгән Мөхәммәтвәли Динмөхәммәтевнең 1915 елгы кульязмасыннан күчереп басылган. Шулай ук әлеге бәет текстының «Казан утлары» журналында һәм М.Нигъмәтҗанов китабында да дөнья күргәнлеге һәм тагын берничә кешедән язып алынган вариантлары булуы искәртелгән[9]. 1983 елгы басмада чыккан текст соңгырак җыентыкларга да кертелде[10].

«Х. С.» имзасы белән чыккан «Сугышма бу? Сугыш бу!» исемле китап, гәрчә бәет дип аталмаса да, аның «Бисмилла дип башласам...» дигән беренче юлларыннан алып, бөтен эчтәлеге тоташ бәет жанрына туры килә. Бу китапта сугыш хәлләре киңрәк планда тасвирланган. Ягъни, сугышның башлану тарихы һәм аның Бельгия, Төркия, Кырым, Кавказ, Австрия – гомумән, төр-

---

[6] Нигъмәтҗанов М. Татар халык җырлары. – Казан: Татар. китап нәшр., 1976. – Б. 54; Нигә бу ызгыш, нигә бу сугыш?: Беренче бөтендөнья сугышы бәете // Казан утлары. – 1978. – №12. – Б. 164–167.

[7] Нигә бу ызгыш, нигә бу сугыш?.. – Б. 164.

[8] Татар халык иҗаты. Бәетләр / төз. Ф.Әхмәтова, И.Надиров, К.Җамалетдинова. – Казан: Татар. китап нәшр., 1983. – Б. 89–95.

[9] Шунда ук. – Б. 303–304.

[10] Татар эпосы. Бәетләр / төз. Ф.Әхмәтова-Урманче. – Казан: «Раннур» нәшр., 2001. – Б. 320–329.

ле фронтлардагы барышы яктыртылган[11]. Әсәрдә җиңү дәртенең ялкыны сизелә.

1914–1917 елларда ук Беренче бөтендөнья сугышы турындагы әллә ничәләп бәетнең китап булып басылып чыгуына татар фольклорын өйрәнүче галимнәр һәм тарихчылар, ни сәбәптәндер, тиешенчә әһәмият бирмәделәр. Мәсәлән, бу сугышка багышланган бәетләр иң күп тупланган 1983 елда чыккан «Бәетләр» китабында, шулай ук сугыш бәетләренә багышлап язылган соңгы мәкаләләрдә дә ул китаплар турында бер сүз дә әйтелмәгән[12]. Үз җирлегебездәге андый чыганакларның кадере-кыйммәте, һичшиксез, югары бәяләнергә лаек.

Герман сугышына багышланган бәетләрнең төрле вариантлары әлеге сугыштан соңгы чорда да чыгып килә. Мәсәлән, Гомәр Толымбай төзеп 1935 елда бастырган бәетләр җыентыгында «Сугыш бәете» исеме астында күләмле бер текст басылган[13]. Әлеге бәетнең бер өлеше 1983 елгы җыентыкта, аннан соң башка китапларда һәм журнал сәхифәләрендә дөнья күрде[14]. 1960 нчы елда дөнья күргән «Бәетләр» китабында бу сугышка бәйле биш бәет тексты бирелгән[15]. 1983 елгы «Бәетләр» җыентыгында Беренче бөтендөнья сугышына багышланган ун бәет[16] һәм шул вакыттагы әсирлек турында дүрт бәет тексты, ике мөнәҗәт басылган иде. Әлеге җыентыклардан тыш, башка бәет текстлары да матбугатта нәшер ителде[17].

---

[11] Х. С. Сугышма бу? Сугыш бу! – Казан: «Мәгариф» матбагасы, 1915. – 15 б.

[12] Татар халык иҗаты. Бәетләр..., 1983. – 351 б; Габдрафикова Л., Салихов Р. Военная повседневность в татарских баитах // Филология и культура. – 2012. – №4 (30). – С. 305–308.

[13] Бәетләр: революциягә кадәргеләр / төз. Г.Толымбай. – Казан: Татгосиздат, 1935. – Б. 92–119.

[14] Татар халык иҗаты. Бәетләр..., 1983. – Б. 73–76; Әхмәтзакиров Мөхәммәтшакир. Сугыш бәете // Казан утлары. – 1997. – №9. – Б. 186–188; Әхмәтзакиров Мөхәммәтшакир. Сугыш бәете // Чын мирас. – 2013. – №6. – Б. 101–108.

[15] Бәетләр / текстларны хәзерләүче, җыентыкны һәм аңлатмаларны төзүче Х.Ярми. – Казан: Татар. китап нәшр., 1960. – Б. 237–255.

[16] Татар халык иҗаты. Бәетләр..., 1983. – Б. 73–102, 104–109, 266–267, 269.

[17] 1914 елгы империализм сугышы турында бәетләр // Совет әдәбияты. – 1939. – №8–9. – Б. 151–154; Тарих мең дә сигез йөз дә: бәетләр һәм

Әмма Беренче бөтендөнья сугышына бәйле бәетләрнең киң катлау укучыларга билгесезләре дә шактый. Гарәп язуындагы татар кульязмалары саклана торган оешмаларда (фәнни китапханәләр, архивлар һәм музейларда), шулай ук шәхси кулларда өйрәнелмичә ята торган дистәләгән бәет текстлары бар. Кайбер дәфтәрләрдә бу сугышка һәм әсирлеккә багышланган бәетләрнең хәтта 7–8 төре бергә тупланган! Сугыш һәм әсирлек бәетләренең бер өлеше халык күңеленә күптәннән кереп урнашкан шигъри калыпларда иҗат ителеп, еш кына шуларның ук көйләренә укылган. Аерым алганда, «Кыйссаи Йосыф» әсәре, «Сак-Сок бәете», Әхмәт Ясәви һәм башка төрки-татар суфый әдипләрнең хикмәтләре, иң популяр мөнәҗәтләр, «Рус-француз сугышы бәете», хәтта Габдерәхим Утыз Имәни һәм Габделҗәббар Кандалый әсәрләре дә Беренче бөтендөнья сугышы турындагы бәет текстлары өчен шигъри шәкел буларак кулланылган мисалларны очратканыбыз бар.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган ядкәрләр арасында Беренче бөтендөнья сугышы бәетләре язылган дәфтәрләр шактый. Андый кызыклы истәлекләр табылып һәм өстәлеп тора. Хәзерге вакытта Милли китапханәдәге кульязмаларда Герман сугышы һәм әсир бәетләренең егермегә якын төре саклана.

«Татар археографиясе» сериясенең шушы – нәүбәттәге чыгарылышында Беренче бөтендөнья сугышына багышланган бәетләрнең бер солдат дәфтәрендә язылганнары тәкъдим ителә.

Бу солдат дәфтәрен Әгерҗе районының Төрдәле мәчетендәге иске китап-язмалар арасыннан, мәчетнең имамы, язучы Габ-

---

мөнәҗәтләр / төз. Ф.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б. 40–44, 127–129; Татар эпосы. Бәетләр / төз. Ф.Әхмәтова-Урманче. – Казан: «Раннур» нәшр., 2001. – Б. 298–338, 342–349; Хөснуллин К. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр: көйләп укуга нигезләнгән жанрлар. – Казан: «Раннур» нәшр., 2001. – Б. 294; Яркәев Г. Әсир дәфтәре / төз.: С.Гыйләҗетдинов, К.Хөснуллин. – Казан: РИЦ «Школа», 2003. – 148 б.; Татар халык иҗаты: хрестоматия / төз. Ф.Урманче, К.Миңнуллин. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 400–402; Австрия зинданнарында туган шигъри хатлар: Әхмәди Җамалетдин улы әсәрләре / кереш мәкалә һәм әсәрләрне басмага әзерләүче А.Гайнетдинов // Чын мирас. – 2013. – №6. – Б. 94–99.

дулла ага Галиевнең рөхсәте белән, 2008 елның 21 декабрендә алган идек. Габдулла ага әлеге бәетләр дәфтәренең хуҗасы Мифтахетдин исемле картны бераз хәтерлим дип һәм әлеге кыйммәтле ядкәрне Бану Кәримуллина тапшырганлыгын да искә алды.

Теркәлгән мәгълүматларга караганда, дәфтәр дошман әсирлеген үтеп, иясе белән бергә ватанга кайткан. Дәфтәрнең 1а кәгазендә мондый язмасы бар: «Ошбу дәфтәр иясе Төрдәле карьясенең Мифтахетдин Габделгалим угылы. Язылды 1915 нче елда, октябрьнең 10 нчы [көнендә]. Германда плиндә. Язгучы – Чөшле каръ[ясенең] Мулламөхәммәд Галим... 1915 нче сәнәдә». Димәк, бу дәфтәрнең хуҗасы Мифтахетдин Габделгалим улы һәм андагы текстларның бер өлеше бүтән якташлары кулы белән дә язылган. Аларның икесе дә Чөшле авылы кешеләре: Мулламөхәммәд һәм Бәдретдин Бәһаветдин улы.

Татарстан Республикасының Әгерҗе районындагы, XVII гасырдан алып XX гасыр уртасына хәтле Төрдәле исеме белән аталып гомер сөргән авыл 1950 нче еллар башыннан үзенә ызандаш Кырынды авылының бер өлеше булып исәпләнә һәм хәзер дә рәсми рәвештә шул исем белән йөртелә. Ә шушы ук дәфтәрдә күрсәтелгән Чөшле – Әгерҗе районындагы татар авылының исеме. Бу авыл халык телендә электән Чөшле (Шөшле) дип йөртелгән, ә әүвәлге һәм хәзерге рәсми атамасы – Яңа Аккуҗа. Төрдәле һәм Яңа Аккуҗа авыллары күрше үк булмасалар да, бу дәфтәр язылган чорда Вятка губернасының Алабуга өязенә кергәннәр. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында (шулай ук Икенче бөтендөнья сугышында да) бер төбәктән бер үк вакытта алынган ир-егетләр, гадәттә, фронтта да бер тирәдәрәк булганнар. Шул сәбәпле Төрдәле кешесе Мифтахетдин дәфтәренә әсирлек гомерләрен бергә кичергән якташлары бәетләр теркәп куюы гаҗәп түгел. Бу дәфтәргә Мифтахетдиннең үз кулы белән язылган соңгы бәет белән чагыштырганда, Чөшле авылының ике кешесе язган текстлар тотрыклы һәм хаталары азрак булу белән аерылып тора. Ягъни, Мифтахетдин үзеннән укымышлырак һәм язулары матуррак булган якташларына үтенеп дәфтәренә яздырткан дип фаразларга мөмкин. Ә бу хәлнең, сугыш шартларына күрә, башка сәбәптән



*Мифтахетдин Габделгалим улының дәфтәре. 1а кәгазь.*

(бәлки, Мифтахетдиннең кулы яраланып, яза алмавыннан) килеп чыккан булуы да бик ихтимал.

Дәфтәрнең 4б–5а кәгазьләрендә язылган мәгълүматка караганда, Мифтахетдин Галимов 1915 елның 26 июль көнендә Варшава шәһәре янында әсирлеккә төшкән. 31 июльдә аларны Германиядәге бер шәһәргә чыгарганнар. Ул нинди шәһәр булуы төгәл әйтелмичә, «гурыт» (город, ягъни шәһәр) дип кенә аталган. Дәфтәрнең 31а кәгазендә рус хәрефләре белән язылган «Айнс-Штимер, Кейрилис, Ревалде, Пост Ревалде Краж, Грауденс» атамаларының дөрес язылышлары шиклерәк булса да, аларның әсирлектә чагында күргән калалары икәнлеген чамаларга мөмкин. Мифтахетдин тоткынлыктан ике мәртәбә: 28 августта һәм 27 сентябрьдә туган иленә хат язып җибәргәнлеген теркәп куйган. Димәк, әсирләр өчен андый мөмкинлек тудырылган. Алман әсирлегендәге татарлар язмышын өйрәнүче тарихчы Искәндәр Гыйләҗев язуынча, «әсирләр хокуклары турында кабул ителгән халыкара конвенцияләр нигезендә, алар туганнарыннан да хат яки посылка ала алган»[18]. Туганнарыннан тыш, сугыш вакытында әсирләргә ярдәм итү буенча төрле хәйрия оешмалары да азык-төлек (шикәр, чәй, сохари, ярмалар), сабын, тәмәке кәгазе, кайчагында эчке киемнәр кебек әйберләрне посылка итеп юллап торган.

Мифтахетдин Галимов үзләренең 1917 елда 17 июньдә Туфлерга килүләре һәм аннан соң ирекле эшкә керешүләре, өенә хатлар җибәрүе турындагы мәгълүматны теркәп куйган. Туфлер дигәне – Франциянең төньягындагы (хәзерге Нор Па-де-Кале регионындагы) шәһәр. Бу кала 1914 елда немецлар тарафыннан басып алынган. Әсирлектәге Галимовларны Туфлерга, күрәсең, ярымирекле хәлдә эшкә җибәргән булганнардыр. Кызганычка каршы, М.Галимов ул хакта тулырак язмаган һәм аның әсирлектән тулаем азат ителеп, илгә кайчан кайтуы да билгесез. Бары тик дәфтәрендәге 1920 елның декабрендә «Нәүфилә туды» дигән язуына караганда, Мифтахетдин Галимов аңа хәтле туган авылына кайткан дип фаразларга мөмкин. Аның әсирлектә теркәлгән

[18] Гыйләҗев И. Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә мөселман әсирләре // Казан утлары. – 2014. – №3. – Б. 170.

язмалары арасында «...получить Галиму Ижбулдину» рәвешендәге, әтисенең адресы да бар (36а кәгазьдә).

Архивлардан эзләнеп ачыклавыбызча, Төрдәле авылының Габделгалим Ишбулдинның Мифтахетдин исемле улы 1888 елда туган. Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында армияне тәэмин итүне көйләү өчен 1917 елда Россиядә уздырылган авыл хуҗалыгы эшчәнлеген исәпкә алу документларында М.Габделгалимов турында мәгълүмат табылды. Бу исәп алу Алабуга өязендә 1917 елның май-июнь айларында уздырылган. Мифтахетдин ул вакытта әтисе хуҗалыгында язылган һәм аның мобилизация буенча 30 ай өйдә юклыгы теркәлгән. Аның 30 яшьлек хатыны һәм 2 яшьлек улы булганлыгы да язылган. Димәк, Мифтахетдин Галимов сугышка 1914 елның ахырында алынган һәм үзе киткәннән соң улы дөньяга килгән икән. 1917 елгы исәп алу документларында язылганнарга караганда, ул вакытта Төрдәле авылының 75 ир-егете мобилизация һәм набор буенча сугышта һәм хәрби хезмәттә булган[19].

Мифтахетдин Галимов дәфтәрендә исеме язылган Чөшле (Яңа Аккуҗа) авылының Бәдретдин Бәһаветдинев (1887 елда туган) 1917 елгы документта мобилизация буенча 36 ай өйдә булмавы, аның 28 яшьлек хатыны барлыгы теркәлгән. Өйдә булмау вакытын исәпләп караганда, Бәдретдин сугыш башлангач та, ягъни 1914 елның җәендә үк, фронтка алынганлыгы ачыклана. Шул ук авылның архив документларында язылган Мулламөхәммәд Нәфыйков та (1887 елда туган) Мифтахетдин дәфтәрендә исеме күрсәтелгән кеше булса кирәк. Дәфтәрдә аның үз исеме тулы укылса да, әтисенең исеме «Галим...» рәвешендә генә таныла, күрәсең, аның фамилиясе Нәфыйков булгандыр дип фаразлыйбыз. 1917 елгы исәп алу вакытында М.Нәфыйковның мобилизация буенча 24 ай дәвамында өендә юклыгы теркәлгән, аның 23 яшьлек хатыны һәм 5 яшьлек улы булган. Димәк, әлеге Мулламөхәммәд

[19] Татарстан Республикасының Милли архивы (ТР МА). – 991 фонд, 1 тасвир, 153 саклану берәмлеге, 155–156 кәгазьләр; 991 фонд, 2 тасвир, 290 сакл. бер., 117–117об. кәгазьләр; Мәрданов Р. Тарихта тибрәлгән Тәбәрле. – Казан: «Тамга» нәшр., 2011. – Б. 180.

сугышка 1915 нче елның язында алынган[20]. Чөшле (Яңа Аккуҗа) авылыннан да 1917 елда сугышта һәм хәрби хезмәттә булучылар саны 75 кешене тәшкил иткән[21]. Гомумән, Төрдәле һәм Яңа Аккуҗа авыллары документлары нигезендә фикер йөрткәндә, яше буенча туры килгән һәм сәламәтлеге яраклы ир-егетләрнең күпчелеге сугышка алынган булган. Кайбер гаиләләрнең берничәшәр кешесе (атасы һәм улы яки бертуган ага-энеләр) сугышта булганлыгы күрсәтелгән. Шул ук вакытта Яңа Аккуҗаның Бәдретдин Бәһаветдинев кебекләрнең тормыш итәр өчен төп чыганагы – мал-терлекләре бөтенләй калмаган һәм чәчелгән игеннәре дә аз булганлыгы күренә. Ягъни, әлеге сугыш Россия империясендә яшәгән бөтен халыкны һәм һәрбер кала-саланы зур хәсрәткә салу белән бергә, мохтаҗлыкка төшергән.

Мифтахетдин Габделгалим улының дәфтәрендә язылган бәетләрне тасвирларга керешкәнче, Беренче бөтендөнья сугышы турында гомуми мәгълүматны һәм дәфтәр иясенең туган төбәге – элекке Вятка губернасының Алабуга өязенең шул чорын кыскача тасвирлап үтик.

***

Беренче бөтендөнья сугышы 1914 елның 15 июлендә башланып, 1918 елның ахырына кадәр дәвам иткән. Ул замандагы иң көчле державалардан ике коалициянең: бер яктан Германия, Австро-Венгрия, Төркия һәм Болгария, ә икенче яктан 1907 елда берләшкән Антанта[22] илләре – Россия, Франция, Бөекбритания, Сербиянең коточкыч бәрелеше нәтиҗәсендә бөтен Европа һәм өлешчә башка кыйтгалар да ут, кан, вәхшәт, ачлык, михнәт эчендә калган. Сугыш барышында Антанта ягына Япония, Италия, Америка Кушма Штатлары һәм башка илләр дә кушылып, бу коалициядәге дәүләтләр саны утыз дүрткә җиткән.

Европадагы союзниклары сугыша башлау сәбәпле, Россиядә

[20] ТР МА. – 991 фонд, 2 тасвир, 338 сакл. бер., 75, 79 кәгазьләр.
[21] ТР МА. – 991 фонд, 2 тасвир, 338, 341 саклану берәмлекләре.
[22] *Антанта* – башта Бөекбритания, Франция һәм патша Россиясе тарафыннан оештырылган, ә Беренче бөтендөнья сугышы вакытында күп сандагы дәүләтләрне берләштергән союз.

18 июльдә гомуми мобилизация игълан ителгән. Польша, Украина һәм Балтыйк буен тартып алу максаты белән 1914 елның 21 июлендә Германия Россиягә сугыш игълан иткән. Патша Россиясе дә Төркияне бүлеп, Кара диңгездән Урта диңгезгә чыгу өчен Дарданелл бугазын үзләштерергә омтылган, шулай ук Константинопольне һәм Австро-Венгриянең бер өлешен тәшкил иткән Галицияне яулап алырга тырышкан. Россия армиясе Балтыйк буе, Галиция һәм Польшада Германия гаскәрләренә, шулай ук Кавказ артында төрек гаскәрләренә каршы сугыша.

1914 елда сугышны чагыштырмача уңышлы алып барган Россия армиясен 1915 елда немецлар шактый чигенергә мәҗбүр иткән. 1915 елның март аенда рус армиясенең Перемышль шәһәрен алуы – ул елдагы иң зур уңышы булган. Шул ук елның апрель аенда немецлар көчле һөҗүм башлагач, бу каланы руслар июнь аенда дошманга калдырып китәргә мәҗбүр була. Корал, артиллерия снарядлары җитмәү, гомумән, тәэминатның начар булуы, немецларның сан ягыннан күплеге (ике мәртәбә артыграк булуы) һәм дошманның көчле артиллерия һөҗүмнәре нәтиҗәсендә рус армиясе Польшаның көньяк өлешеннән 1915 елда чигенергә мәҗбүр була. Аннан соң немецлар рус армиясен Польшаның төньяк тарафыннан да кысрыклый. Ягъни, 1915 елның 26 июнендә Польшада Висла һәм Буг елгалары арасында герман армиясе һөҗүм башлаган. 4 августта Варшаваны немецлар алган. Шул сәбәпле Россия армиясендә гомуми рух төшенкелеге күзәтелгән һәм сугышчылар дошманга күпләп пленга бирелгәннәр. Мифтахетдин Галимов, үз дәфтәрендә 1915 елның 26 июлендә (Польшаның төньягында немецлар һөҗүме башланганнан соң нәкъ бер айдан) әсирлеккә төшүләрен язып куйган.

1916 елда Антанта илләре дошман якның һөҗүмнәрен һәм каршылыгын сындыруга ирешкән. Шул ук вакытта Россия гаскәрләре төрекләр белән сугышта уңыш казанган. Ләкин Россиядә 1917 елның февралендәге революция хәрәкәте нәтиҗәсендә, армия таркала башлый һәм фронттагы хәлләр кискенләшә. 1918 елның 3 мартында Россия белән Германия арасында Брестта төзелгән солых нигезендә Совет Россиясе сугыштан чыккан. Брест

солыхы буенча Россия Польшаны, Балтыйк буен һәм Украина белән Белоруссиядәге җирләренең бер өлешен югалткан.

Беренче бөтендөнья сугышына катнашкан һәм җәлеп ителгән – Җир шарындагы 87% халык яшәгән илләрнекен бергә исәпләгәндә, барлыгы 74 миллион чамасы кеше мобилизацияләнгән, 10 миллион тирәсе гаскәриләр һәм 12 миллионлап гади граждан һәлак булган, 55 миллион тирәсе кеше яраланган һәм гарипләнгән. Антанта дәүләтләренең 4 миллионнан артык сугышчысы әсирлеккә төшкән.

Тарихта аңарчы күрелгән дәһшәтләр белән чагыштырганда, иң күп үлем һәм җимереклекләргә китергән бу сугыш Россия империясе өчен аеруча зур хәсрәт булган. 1914–1915 елларда Россиядә 12 миллионга якын (кайбер белгечләр язуынча, 16 миллионлап) ир-егет сугышка мобилизацияләнгән. Шуларның ун процент чамасы өлешен мөселман төрки-татарлар тәшкил иткән. Россиядәге мөселман төрки-татарлардан бу сугышка 1–1,5 миллион кеше фронтка алынган[23]. Россия армиясенең 2,5 миллион чамасы гаскәри ир-егетенең үлеме, тагын шул кадәр үк сугышчыларының әсирлеккә эләгүе, толлар, ятимнәр, ачлык, ил хуҗалыгының җимерелүе, хакимият кризисы һәм бүтән бәхетсезлекләр бергә укмашып, яшәеш агымын бик нык какшаткан.

Сугышка мобилизацияләнүчеләр саны буенча Вятка губернасы бөтен Россиядә өченче урында торган. Губернада беренче мобилизация үткәрелгәндә (1914 елның 27 июлендә) биш өяздән, шул исәптән Алабуга өязеннән, хәрби хезмәт үтеп кайткан запастагы 45 мең кеше сугышка алынган. Икенче чакырылыш көненнән (3 августтан) бөтен губернадан тагын 70 мең кеше фронтка озатылган. Шуларның 90 проценты крестьяннар булган һәм бер айдан да аз вакыт эчендә Вятка губернасындагы авыллар 100 мең крестьяннан (эшкә яраклы ир-атларның 28%) мәхрүм калган. Сугышка мобилизацияләү вакытының авылдагы кайнар эш чорына туры килеп, бик күп хуҗалыклар төп эшче көченнән аерылу сәбәпле, бөлгенлеккә төшкәннәр һәм ачлыкка дучар булганнар.

[23] История татар: с древнейших времён. В семи томах. Т. VII: Татары и Татарстан в ХХ – начале XXI в. – Казань: Ин-т истории им. Ш.Марджани, 2013. – С. 196.

Өстәвенә, крестьяннарны солдатка алу белән бергә атлар һәм сбруйлар да мобилизацияләнгән. Бу хәл авылда яшәүчеләрне тагын да хәерчеләткән.

Алабуга өязендәге татар авылларында да хуҗалыкның бөтен эшләре хатын-кызлар, картлар һәм балалар өстенә төшкән. Җитмәсә, аларны Ижевск корал заводы өчен урман кисүгә мәҗбүриләп эшкә куып торганнар. Россиядә икмәк һәм, гомумән, азык-төлек кризисы елдан-ел көчәйгән. Авыллардагы запас ашлыкларның бер өлеше армия һәм дәүләткә җыеп алынган. 1917 елның август аенда ачлыктан интегүче Түбән Новгород, Владимир һәм Кострома губерналарыннан ашлык алырга килгән меңләгән кеше елга юлы буенча Камадагы пристаньнәрдә һәм тимер юл буенча станцияләрдә төшеп, Алабуга һәм Сарапул өязләрендәге авылларга килеп тулган. Хәлләр аеруча киеренкеләнгән. Бу як авылларына кораллы хәрбиләр китерелгән. Җирле халык белән Түбән Новгородтан килгән меңләп кеше арасында тимер юл станцияләре һәм пристаньнәрдә бәрелешләр булган. Алабуга өяз идарәсе спекулятив бәягә сатылган барлык ашлыкны армия өчен көч белән йолып алу турында карар чыгара. Өстәвенә, волостьлардан җыелган икмәк өчен тиешле акча бөтенләй түләнмәгән, авыллардагы запас амбарларда һәм халыкның үзендә ашлык беткән. Шулай итеп, 1917 елның көзендә крестьяннарның җир өчен көрәше һәм хөкүмәткә ашлык бирүдән баш тартуы көчәя бара. Авыл хуҗалыгы түбәнгә тәгәри. 1916 ел белән чагыштырганда, 1917 елда Вятка губернасындагы чәчүлек җирләр өчтән бер өлешкә кимегән.

Һәр көндә үлем белән очрашкан солдатларга туган якларындагы, үз хуҗалыгындагы менә шундый четерекле хәлләр турындагы хәбәрләр ирешеп торган. Сугыш мәхшәре эчендәге бичара солдатларга гаилә хәсрәте дә зур борчулар тудырган. Фронтовиклар командирларына, туган җирләрендәге земстволарга, волость идарәләренә ачлыктан интегүче үз гаиләләренә ярдәм итүне сорап, меңнәрчә хатлар һәм үтенечләр язганнар. Тик аларны канәгатьләндерү мөмкин булмаган.

Сугышта катнашып исән калган солдатлар, илдәге революцион үзгәрешләрдән соң, 1917 елның ноябрь-декабрендә ту-

ган җирләренә кайта башлаганнар. Шактые 1918 елның язында, Брест солыхыннан соң гына кайткан.

Герман сугышында меңнәрчә татар ир-егетләре дә һәлак булган, гарип-горабага әйләнгән, ничаклы балалар ятим һәм хатыннар тол калган. Сугыш афәтенең ни дәрәҗәдәге мәхшәр икәнлеген ул заманда яшәгән кешеләр бик яхшы аңлаганнар. Тик Герман сугышы туктап җитәр-җитмәс, аның коточкыч фаҗигаләренә 1918 елда илдәге гражданнар канкоешы тоташып киткән.

Илдәге барлык халык өчен дәһшәтле булган бу сугышның зур фаҗигасе, монысыннан да куркынычлырак Икенче бөтендөнья сугышының вәхшәте һәм хәсрәте аркасында гына бераз онытылган.

***

Беренче бөтендөнья сугышы чорында алман әсирлегендә булган татарларның төгәл саны билгесез. Бу мәсьәләне махсус өйрәнгән тарихчы И.Гыйләҗев андый язмышка юлыгучылар дистәләгән мең булган дип яза. Шулай ук ул Алмания территориясендә урнашкан кимендә 100 хәрби әсирләр лагеренда татар солдатлары булуын белдерткән[24]. Ул чор әсирләре турында мәгълүматлар матбугатта берникадәр чыгып килә. Дөрес, аларның күбесе Берлин янындагы Вюнсдорф һәм Цоссен шәһәрчекләре арасында мөселман әсирләре өчен махсус төзелгән ике лагерьга багышланган[25]. Бу лагерьлар бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә

[24] Гыйләҗев И. Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә мөселман әсирләре // Казан утлары. – 2014. – №2. – Б. 129.

[25] Уразманов С. Германиядә татар театры // Татар театры: 1906–1926. Театр мәҗмугасы / төз.: Парсин М., Мутин М., Баязидский З. – Казан: Татарстан дәүләт нәшр., 1926. – Б. 171–172; Мәхмүтов Һ., Илялова И., Гыйззәт Б. Октябрьгә кадәрге татар театры: очерклар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1988. – Б. 341–342; Мәһдиев М. Герман җире яшел үлән: Беренче бөтендөнья сугышы чорында татар солдатларының әсирлектәге тормышыннан бер сәхифә // Идел. – 1990. – №7. – Б. 30–34; Гарифуллин Д. Алман җирендә «Татар иле» // Социалистик Татарстан. – 1990. – 9 сентябрь; Гарифуллин Д. Алман илендә әсир татарлар // Социалистик Татарстан. – 1991. – 21 июнь; Гарифуллин Д. Мөхтәрәм татар // Ватаным Татарстан. – 1993. – 26 март; Гарифуллин Д. Алман җирендә «Татар иле» // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1996. – №1/2. – Б. 221–225; Гилязов И. «Продолжать работу, пока

булганлыктан, аларны бер исем астында Вюнсдорф лагере дип атау да гамәлдә булган[26]. Мөселман әсирләре өчен махсус лагерьлар төзү мәсьәләсе 1914 елда – сугыш башлану белән үк туган. Аларга әсирләр туплау 1915 елның җәенә хәтле дәвам иткән.

Мәкаләләрдә язылганнарга караганда, Вюнсдорф лагерендагы татар әсирләре кырыклап командага бүленеп, баракларда яшәгәннәр. Анда 1915 елда зур гөмбәзле, биек манаралы мәчет төзелгән, театр өчен аерым бина булган, оркестр һәм китапханә

тюрко-татарская нация не станет независимой от европейской культуры» // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1996. – №3/4. – С. 193–199; Гайнетдинов Р. Тюрко-татарская политическая эмиграция: начало XX века – 30-е годы: исторический очерк. – Набережные Челны: Камский издательский дом, 1997. – С. 55–59; Гилязов И. Вюнсдорфская мечеть: эпизод исламской жизни в Германии, 1915–1930 гг. // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1997. – №1/2. – С. 178–187; Гилязов И. «Германия воспринимает вас не как военнопленных, а как своих гостей» // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2002. – №1/2. – С. 250–255; Уразманов С. Германиядә татар театры // Татар театры: 1906–1926. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 180–181; Хөснуллин И. Алман җирендә татар зираты // Ватаным Татарстан. – 2004. – 23 апрель; Фазылҗанова Ф. Германиядәге мөселманнар зираты // Шәһри Казан. – 2004. – 28 апрель; Гилязов И. Легион «Идель-Урал»: представители народов Поволжья и Приуралья под знаменами «третьего рейха». – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – С. 82–87; Мостафин Р., Фәттахов Р. «Герман җире кара үлән...»: тарихыбызның онытылган бер сәхифәсе // Татарстан. – 2006. – №7. – Б. 44–47; Мустафин Р., Фаттахов Р. Чёрная трава Германии: забытая страничка истории // Татарстан. – 2006. – №7. – С. 44–47; Наше прошлое – наше дело: специальная акция журнала «Татарстан» // Татарстан. – 2006. – №9. – С. 62; Вагизова В. Последние почести тем, кто долгие годы был в забвении // Татарстан. – 2006. – №9. – С. 63–65; Мустафин Р. Татарский самодеятельный театр в Германии: страницы истории // Татарстан. – 2006. – №9. – С. 66; Список военнопленных татар, скончавшихся в годы Первой мировой войны в немецком лагере для военнопленных Вюнсдорф и похороненных на кладбище Церенсдорф // Татарстан. – 2006. – №9. – С. 67–68; №11. – С. 48–49; Шәфигуллин Р. Хәлими һәм ефрейтор Адольф Гитлер // Ватаным Татарстан. – 2009. – 23 гыйнвар; Гатауллина Л. Религиозно-политическая пропаганда среди Российских военнопленных-мусульман в Германии (1914–1922): автореф. дисс. ... канд. истор. наук. – Казань, 2011. – 23 с.; Гыйләҗев И. Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә мөселман әсирләре // Казан утлары. – 2014. – №2. – Б. 128–132; №3. – Б. 167–172; №4. – Б. 168–173.

[26] Гилязов И. Легион «Идель-Урал»... – С. 83.

оештырылган. Татар әсирләре өчен 1915–1918 елларда «Әлҗиһад» һәм 1918 елдан «Яңа тормыш», 1919–1920 елларда «Татар иле» исемнәрендәге газеталар, китаплар да чыгарылган[27]. Бу лагерь, Алман хөкүмәтенең мөселман хәрби әсирләре өчен император Вилһельм әмере белән махсус сәяси-пропаганда максатларында оештырылган. Галимнәр язуынча, Алмания җитәкчелеге әлеге лагерьны мөселман илләре алдында гына түгел, ә мөселманнар яшәгән Антанта дәүләтләре өчен дә алман индустриясенең һәм тәртибенең бөеклеген пропагандалау чарасы итеп караган[28]. Вюнсдорф лагерендагы тоткыннарны Антантаның колониаль буйсынуындагы илләрендә мөселманнарны дин нигезендә берләштереп Алманиянең дошманнарын эчтән таркату, төрле баш күтәрүләр оештыру, хәтта революцион күтәрелешкә әзерләү максаты куелган булган[29]. Шулай ук мөселман әсирләреннән хәрби берләшмәләр оештырып, аларны Антанта илләренә каршы сугышта куллану нияте дә хөкем сөргән. Бу мәсьәләдә төп ышаныч – Германиянең союзнигы һәм ул чорда дөнья мөселманнарының үзәге буларак танылган Төркиягә йөкләнгән. Төркия, үз нәүбәтендә, 1914 елның ноябрендә Бөекбритания, Россия һәм Франциягә каршы изге сугыш – җиһад игълан иткән. Алманиянең мөселман әсирләренә карата сәясәте турында И.Гыйләҗев хезмәтләрендә һәм соңгы күләмле мәкаләсендә тәфсилләп аңлатылган[30], шунлыктан ул мәсьәләгә монда киңәеп тукталу ихтыяҗы юк.

Вюнсдорфтагы әсирләр лагеренда татарлардан тыш, Антанта илләренең армияләреннән әсирлеккә төшкән төрле халык вәкилләре дә тотылган. Россия армиясендәге Идел-Урал буе татарлары һәм шул ук төбәкнең башка халык вәкилләре, әрмәннәр белән грузиннар, нигездә, «Виноград тавындагы лагерь»да

---

[27] Насыров Т. Татарская эмигрантская пресса // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2004. – №2. – С. 119–120.

[28] Гайнетдинов Р. Тюрко-татарская политическая эмиграция... – С. 56; Гилязов И. «Продолжать работу... – С. 193–194; Гатауллина Л. Религиозно-политическая пропаганда... – 23 с.

[29] Гилязов И. Вюнсдорфская мечеть... – С. 180; Гилязов И. Легион «Идель-Урал»... – С. 83.

[30] Гыйләҗев И. Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә... – №2. – Б. 128–132; №3. – Б. 167–172; №4. – Б. 168–173.

(Weinberglager), ә «Ярымай лагере»нда (Halbmondlager) Көнбатыш һәм Төньяк Африкадагы, Һиндстандагы француз һәм инглиз колонияләре әсирләре тупланган[31]. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Вюнсдорфтагы «Ярымай лагере» белән Цоссендагы «Виноград тавындагы лагерь»да 1916 елда 15 мең мөселман әсире тотылган. Шулардан Вюнсдорф лагеренда 4000 әсир булган. Вайнберг лагерендагы мөселман әсирләренең төрле вакыттагы гомуми саны 10–13 меңне тәшкил иткән[32]. Бу лагерьлардагы тоткыннар әсир буларак түгел, ә Алман иленең кунаклары кебек сыйфатланган. Аларда әсирләрне яхшы ашату һәм киендерү, алар белән яхшы мөгамәлә кылу, чагыштырмача иркле яшәү мөмкинлеге тудыру каралган. Чынлыкта да, әлеге лагерьлардагы әсирләр башка тоткыннар кичергән күп төрле җәфаларны күрмәгәннәр[33].

Немец лагерьларындагы әсир мөселманнарны «җиһад»ка өндәү 1916 елда туктатылган. Алманлыларның бу нияте тормышка ашмаган, Россия мөселманнары немец пропагандасына бирешмәгәннәр.

Ләкин Германиянең бөеклеге һәм Шәрык-мөселман дөньясына карата бик дустанә мөнәсәбәттә булуын агитацияләү эшчәнлеге туктатылмаган. Моның бер дәлиле итеп, 1918 елда Берлинда татар телендә басылып чыккан «Алмания – Шәрык мөнасәбате дөвәлийәсенең үткән вә хәзерге замандагы сафахате белән истикъбальдәге тәрәккыйсе» (Алмания – Шәрык дәүләтләре мөнәсәбәтләренең үткән һәм хәзерге замандагы чагылышы белән киләчәктәге тәрәккые) исемле китапны атарга мөмкин. «Яңа Шәрык көтепханәсенең татарча көллияте асаре» сериясеннән «Беренче китап» сыйфатында нәшер ителгән бу җыентык зур форматта, 72 бит күләмендә. Аның исеме арткы тышлык битен-

---

[31] Вюнсдорфский лагерь // Татарский энциклопедический словарь. – Казань: Ин-т Татарской энцикл., 1999. – С. 128; Вюнсдорф лагере // Татар энциклопедия сүзлеге. – Казан: Татар энцикл. ин-ты, 2002. – Б. 151; Гилязов И. «Германия воспринимает вас... – С. 250; Гилязов И. Легион «Идель-Урал»... – С. 83.

[32] Гилязов И. Легион «Идель-Урал»... – С. 84; Гатауллина Л. Религиозно-политическая... – С. 16.

[33] Гатауллина Л. Религиозно-политическая пропаганда... – С. 16.

дә немец телендә дә бирелгән[34]. Мәсьәлә тулырак күзаллансын өчен әлеге китапны кыскача тасвирлап үтәбез. Китапта М.Вольф, Фридрих Пршински, Һартман, фон Янсон, Шпатч, Карл Папе... – барлыгы 16 авторның (профессор, доктор, генерал һ.б.) Шәрык һәм Германия арасындагы тарихи, сәяси, мәдәни, икътисадый багланышларга багышланган мәкаләләре тупланган. Китап татар теленә Фәүзия ханым Габдеррәшид тарафыннан тәрҗемә ителгәнлеге күрсәтелгән. Мәкаләләр арасында «Русия вә Шәрык», «Дустлык мөнәсәбәтләренең ныгу ихтималлары», «Алман зирагате», «Алман урманчылыгы», «Алман мәгарифе», шулай ук Беренче бөтендөнья сугышы, Шәрыкка бәйле сәнгать әсәрләре, сәламәтлек саклау, сугыш инвалидларын дәвалау һәм башка темалардагы мәкаләләр бар. Китап бик яхшы сыйфатлы кәгазьдәге 12 данә фото һәм иллюстрацияләр белән бизәлгән. Алар арасында «Пруссия падишаһы Зур Фридрих», «Солтан Мостафа ханның Зур Фридрихка җибәргән бер намәсе», «Алман шагыйре Гёте», «Пруссия падишаһысы Өченче Фридрих Вилһельм», «Сугышта бер аяксыз калган алман гаскәрләренең жимнастик ясаулары», «Сугышта кулсыз калган гаскәрнең сонгый кул белән су ташуы», «Берлин сарае: 1914 елда Алмания – Төркия иттифакы имза ителгән ак зал» һ.б. бар. Бу китапны тәрҗемә иткән Фәүзия ханым – Вюнсдорфтагы мәчеттә берара имам вазыйфаларын үтәп торган мәшһүр дини, иҗтимагый-сәяси эшлекле, әдип һәм нашир Габдеррәшид Ибраһимовның (1857–1944) кызы булса кирәк.

Германия һәм Совет Россиясе арасындагы 1918 елның 3 мартында имзаланган Брест солыхы нәтиҗәсендә, әсирләр үз илләренә репатриацияләнергә тиеш булган. Ләкин шул елның ноябрендә Германиядә революция кабыну сәбәпле Брест килешүендә каралган мәсьәләләр гамәлдән чыгарылган. Россиянең мөселман хәрби әсирләренең барысы да туган илгә тиз генә кайта алмаган әле. Дамир Гарифуллин язуынча, 1919 ел

[34] Алмания – Шәрык мөнасәбате дөвәлийәсенең үткән вә хәзерге замандагы сафахате белән истикъбальдәге тәрәккыйсе = DEUTSHLAND UND DER ORIENT. IHRE BEZIEHUNGEN IN VERGANGENHEIT GEGENWART UND ZUKUNFT. TATARISHE BÜCHEREI BAND I VERLAG «DER NEUE ORIENT». G. M. B. H. – BERLIN, 1918.

ахырында Германиядә өч мең биш йөзләп татар әсире булган[35]. Вюнсдорф лагерендагы әсирләр 1921 елның июленә туган илләренә озатып бетерелгән һәм бу тоткынханә шуннан соң гына – 1922 елның 1 маенда ябылган[36]. Журнал шәкелендәге «Татар иле» газетасының басылып чыккан сигез саны бергә төпләнеп һәм катыргы белән тышланып, илләренә кайтучы һәр татар әсиренә бирелгән. Әсирлектән кайтучылар һәм аларның туганнарының кулында бу газетаның нөсхәләре, сирәк булса да, сакланган[37]37. Лагерьда һәлак булган татарлар Вюнсдорф янындагы мөселман хәрбиләре зиратында җирләнгән. Анда барлыгы 2700 тирәсе кешенең кабере булып, шулардан 1100 кабер Россия мөселманнарыныкы икән[38]. Вюнсдорфтагы зиратның мөселман өлешен тәртипкә китерү мәсьәләсендә «Татарстан» журналы 2006 елда махсус хәйрия акциясе игълан иткән иде[39]. Шул ук журналның Германиядәге штаттан тыш корреспонденты Венера Вәгыйзова немец хәрби архивларыннан тапкан әсирлектә вафат булган йөзләрчә татар кешесенең исемлеге дә басылды[40].

Татар матбугатында Вюнсдорф лагере турында шактый күләмле мәгълүматны, беренчеләрдән буларак, язучы Мөхәммәт Мәһдиев бастырган иде. Ул әсирләрнең яшәеш-көнкүрешләрен,

---

[35] Гарифуллин Д. Алман җирендә «Татар иле» // Гасырлар авазы = Эхо веков... – Б. 222.

[36] Гилязов И. «Продолжать работу... – С. 194; Гилязов И. Вюнсдорфская мечеть... – С. 181–182; Гатауллина Л. Религиозно-политическая пропаганда... – С. 4.

[37] Насыров Т. Татарская эмигрантская пресса... – С. 120; Мәһдиев М. Герман җире яшел үлән... – Б. 30–34; Гарифуллин Д. Алман җирендә «Татар иле» // Социалистик Татарстан. – 1990. – 9 сентябрь; Гарифуллин Д. Алман җирендә «Татар иле» // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1996. – №1/2. – Б.221–225.

[38] Гилязов И. Легион «Идель-Урал»... – С. 86.

[39] Мостафин Р., Фәттахов Р. «Герман җире кара үлән...»... // Татарстан. – 2006. – №7. – Б. 47; Мустафин Р., Фаттахов Р. Чёрная трава Германии... // Татарстан. – 2006. – №7. – С. 47; Наше прошлое – наше дело: специальная акция журнала «Татарстан» // Татарстан. – 2006. – №9. – С. 62.

[40] Список военнопленных татар, скончавшихся в годы Первой мировой войны в немецком лагере для военнопленных Вюнсдорф и похороненных на кладбище Церенсдорф // Татарстан. – 2006. – №9. – С. 67–68; №11. – С. 48–49.

мәдәни һәм агарту эшләрен, нигездә, «Татар иле» газетасында дөнья күргән язмалар һәм шулай ук хатирәләр буенча тасвирлады[41].

Беренче бөтендөнья сугышы әсирлегенә бәйле, Вюнсдорф лагереннан башка төр публикацияләр дә ара-тирә дөнья күреп тора. Мәсәлән, шул ук М.Мәһдиев Мюнхен шәһәре янындагы Пухһайм шәһәрчегенең мөселман зиратында 1915–1919 елларда җирләнгән 42 татар хәрби әсиренең исемлеген бастырып чыгарган иде[42]. Мәһдиевкә ул мәгълүматларны Мюнхенда яшәүче милләттәшебез Фәридә Хәмид тапшырган булган. Әлеге Пухһайм зиратында татар әсирләре истәлегенә куелган кабер ташының бүгенге күренешен И.Гыйләҗев бастырды[43].

Австриядәге Эстергом һәм Эгер шәһәрләре янындагы лагерьларда тотылган татар әсирләре белән галимнәр дә аралашканлыгы мәгълүм. Фольклорчы Игнац Кунош (1860–1945) татарларның авыз иҗаты әсәрләрен (җырлар, әкиятләр) өйрәнгән, тоткыннарның тормышы турында махсус мәкаләләр язган[44]. Ул

---

[41] Мәһдиев М. Герман җире яшел үлән... – Б. 30–34.

[42] Мәһдиев М. Алман-кырда сөякләр ята // Ватаным Татарстан. – 1993. – 26 март.

[43] Гыйләҗев И. Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә... – №3. – Б. 172.

[44] Kazantatarische Volkslieder / Auf Grund der Sammlung von Ignac Kunos; herausgegeben von Zsuzsa Kakuk. – Budapest, 1980; Кунош И. Мөселман хәрби әсирләре лагерьларындагы эш турында / төрек теленнән С.Гыйләҗетдинов тәрҗ. // Мирас. – 1992. – №5. – Б. 100–108; Шул ук // Яркәев Г. Әсир дәфтәре / төз.: С.Гыйләҗетдинов, К.Хөснуллин. – Казан: РИЦ «Школа», 2003. – Б. 110–122; Шул ук // Түгәрәк уен. – 2012. – №1. – Б. 28–31; Әсирлектән кайткан әкиятләр / кереш мәкалә авторы һәм текстларны журнал өчен хәзерләүче Л.Җамалетдин // Мирас. – 1993. – №2. – Б. 86–90; №3. – Б. 114–124; №4. – Б. 121–126; №5. – Б. 124–131; №6. – Б. 97–102; №7. – Б. 90–94; №9. – Б. 117–118; №10. – Б. 114–117; №11. – Б. 122–125; №12. – Б. 113–119; 1994. – №1. – Б. 94–96; №2. – Б. 98–100; №3. – Б. Б. 96–101; №4. – Б. 81–83; №7–8. – Б. 105–109; №9. – Б. 71–74; №10. – Б. 92–95; №11–12. – Б. 89–92; 1995. – №1–2. – Б. 124–127; №7–8. – Б. 102–106; №9. – Б. 69–76; №11–12. – Б. 89–92; Кунош И. Татар әсирләре янында / Л.Җамалетдин кереш сүзе белән, урысчадан Р.Зәйдулла тәрҗ. // Идел. – 1995. – №7. – Б. 36–41; Кунош И. В лагере татарских пленных / пер. с венгерского Х.Ягковского; подготовил к печати Л.Замалетдинов // Идель. – 1995. – №7–8. – С. 46–51.

булган лагерьларда күп меңләгән татар һәм башка мөселман әсирләре тотылган.

Матбугатта чыккан материаллардан элекке Вятка губернасының Малмыж өязе (хәзерге Татарстанның Балтач районындагы) Куныр авылыннан сугышка алынган Солтангәрәй Хәбибуллинның көндәлек дәфтәре һәм әсирлектәге фоторәсемнәрен дә әйтергә тиешбез[45].

«Әсир дәфтәре» исеме белән китап булып чыккан басма аерым игътибарга лаек[46]. Бу җыентыкта Оренбург ягы татарларыннан Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан солдат Гыйззәтулла Яркәевнең Австро-Венгриядәге мөселман әсирләре лагерьларында язылган бәет һәм мөнәҗәтләре, Самара губернасы татарларыннан Гатиятулла Әхмәдуллинның сугыш һәм әсирлек хатирәләре, венгр галиме тюрколог Игнац Куношның «Мөселман хәрби әсирләре лагерьларындагы эш» дигән мәкаләсе тупланган. Г.Әхмәдуллин язмалары кабатлап та басылды[47].

Герман сугышында немец әсирлегенә эләккән татар солдатларының фоторәсемнәре матбугатта чыгып торганлыгын да искә алып китәргә кирәк. Тик ул фотолар төрле максатларда төшерелгән. Вюнсдорфтагы әсир мөселманнарның пропагандистик лагерьларында төшерелгәннәре аеруча үзенчәлекле. Мәсәлән, төркем-төркем кешеләрнең ак якалы күлмәкләр, костюм, эшләпәләр кигән, галстуклар һәм чылбырлы сәгатьләр тагып төшерелгән өч фоторәсеме «Алманиядәге татар әсирләре» дип, «Гасырлар авазы» журналында басылып чыккан иде[48]. Шул ук лагерьдагы мәһабәт мәчет сурәте һәм мәчет мәйданында гает намазы, татар әсирләре, столярлык остаханәсендәге татарлар, мөселман зира-

45 Ислаев Ф., Нәккаш Н. Солтангәрәй Хәбибуллин – Беренче бөтендөнья сугышы әсире // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2001. – №1/2. – Б. 152–157.

46 Яркәев Г. Әсир дәфтәре / төз.: С.Гыйләҗетдинов, К.Хөснуллин. – Казан: РИЦ «Школа», 2003. – 148 б.

47 Әхмәдуллин Г. Сугыш хатирәләре // Түгәрәк уен. – 2012. – №1. – Б. 32–39.

48 Гарифуллин Д. Алман җирендә «Татар иле» // Гасырлар авазы = Эхо веков... – Б. 222.

ты һәм башка күренешләр дә дөнья күрде[49]. Галимнәр андый фоторәсемнәрне Германия пропагандасының уникаль чыганаклары дип бәялиләр[50].

Ә Эстергом лагерендагы татар әсирләренең күмәк һәм ялгыз төшкән рәсемнәре[51], шулай ук С.Хәбибуллинның башка әсирләр белән бергә төшкән фотолары башкачарак. Хәбибуллин турындагы публикацияне басмага әзерләүчеләр әсирләрнең үзләрен саклаган кораллы немец солдаты белән бергә төшкән фотосына карата «әле ул чорда әсирләрне Бөек Ватан сугышы елларындагы шикелле кимсетү-җәберләү булмаганлыгы күренеп тора» дигән ялгыш нәтиҗә ясаганнар[52]. Юкса алманлыларның Беренче бөтендөнья сугышы әсирләренә карата кылган җәбер-золымнары һәм вәхшилекләре турында шушы басмадагы бәет текстларыннан да укып белергә мөмкин. Андый мәгълүматлар башка чыганакларда да бар.

Беренче бөтендөнья сугышында әсирлеккә эләккән рус армиясе солдатларын фотога төшерү турында Гатиятулла Әхмәдуллинның язмасы игътибарга лаек. Истәлекләрендә ул үзләренең әсирлеккә эләккәч немецларның кыр штабына китерелеп, анда штаб башлыгының: «...барыгыздан да өчәр карточка алына, берсе үзегезгә бирелә, берсе бездә жандармнар отделениесенә бирелә, берсе үзегезнең Москвага җибәрелә» дип аңлатуын теркәгән[53]. Бу, күрәсең, немецларга әсирлеккә төшүчеләргә карата кулланылган гомуми чара булгандыр. Чөнки берничә кешенең бергәләп әсирлектә чакта төшкән фотоларын күргәнебез бар. Шундыйларның берсен – элекке Вятка губернасының Алабуга өязенә кергән (хәзерге Әгерҗе районындагы) Тәбәрле авылы кешесе Нәбиулла Азиевның биш иптәше белән 1916 елда немецларда тоткынлыкта

---

[49] Гилязов И. Вюнсдорфская мечеть... – С. 178–179; Гилязов И. «Германия воспринимает вас... – С. 250–254; Гыйләҗев И. Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә... – №3. – Б. 168–171; №4. – Б. 170–173.
[50] Гатауллина Л. Религиозно-политическая пропаганда... – С. 7, 12.
[51] Кунош И. Мөселман хәрби әсирләре лагерьларындагы... – Б. 103–105; Шул ук // Яркәев Г. Әсир дәфтәре... – Б. 122; Кунош И. Татар әсирләре янында... – Б. 36.
[52] Ислаев Ф., Нәккаш Н. Солтангәрәй Хәбибуллин... – Б. 154.
[53] Яркәев Г. Әсир дәфтәре... – Б. 97; Әхмәдуллин Г. Сугыш хатирәләре... – Б. 35.

төшерелгән һәм үзе белән алып кайткан фотосын бастырган да идек[54].

Галимнәр яисә кызыксынучы башка милләттәшләребез андый фоторәсемнәрне туплауга иҗтиһад итсә, бик файдалы һәм кирәкле гамәл булыр иде. Чөнки Германия архивларында тупланган һәм сирәк белгечләрнең генә теше үтәрдәй документлар нигезендә пропагандистик мөселман әсирләре лагерьлары турында төпле мәкаләләр һәм хезмәтләр язылып та, үз җирлегебездәге чыганакларның кулланылмавы һәм исәпкә алынмавы аянычлы күренеш. Хәтта, әйтергә кирәк, пропагандистик материалларга нигезләнеп язылган һәм даими чыгып килә торган мәкаләләр берьяклырак фикер урнашуга этәрә. Гүяки, Беренче бөтендөнья сугышы вакытындагы татар әсирләре концерт-спектакль куеп, җырлап, газета-журнал чыгарып, динне тиешенчә тотып, остаханәләрдә төрле тәтиләр ясап, хезмәтләре өчен азмы-күпме акча да алып, фырт киенеп, алкогольсез сыра эчеп рәхәт чигеп ятканнар. Югыйсә, бөтен әсирләр дә гадәттән тыш шартларда тотылмаган бит. Чөнки Вюнсдорфтагылары Германиядәге татар әсирләре тотылган 100 лагерьның икесе генә, ләбаса. Калганнары турында хәбәребез бөтенләй юк диярлек. Бу турыда И.Гыйләҗев тә урынлы искәрткән. Ягъни, ул: «Бу махсус пропагандистик лагерьлар турында мәгълүматлар күбрәк сакланганга күрә, аларны өйрәнү чагыштырмача җиңелрәк, ләкин башка урыннарда әсирлек авырлыкларын кичерергә мәҗбүр булган милләттәшләребез язмышын да онытырга ярамый», – ди һәм Вюнсдорфтагы әсирләрне күздә тотып, аларны «барлык татар әсирләренең кечкенә бер өлеше генә» дип тәгаенли[55]. Ләкин бу авторның шул ук лагерьларга багышлап язган мәкаләсен «Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә мөселман әсирләре» дип атавы һәм мәкалә бүлекләренең берсен «Алманиядә лагерь тормышы» дип исемләве – гомуми әсирләр тормышын тасвирлаган кебек аңлашыла.

Сугышта ничәләп татар сугышчысы әсирлектә булды икән, алар кайсы шәһәрләрдәге лагерьларда тотылган, бүтән рәвештә асралучылар күпме кеше булуы турында киләчәктә галимнәре-

---

[54] Мәрданов Р. Тарихта тибрәлгән Тәбәрле... – Б. 381.
[55] Гыйләҗев И. Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә... – №3. – Б. 169.

без төгәлрәк итеп язарлар дип ышанасы килә. Гомумән, сакланып калган көндәлекләрдән, хатлардан, бәетләрдән һәм башка төр язма мәгълүматлардан әсирләрнең тормыш-көнкүрешләрен берникадәр күзалларлык тасвир тудырырга мөмкин. Югыйсә, үзебезнең галимнәрнең кулы ирешердәй, якындагы кыйммәтле беренчел чыганакларны файдаланмау – аларны санга сукмауга тиң. Галимнәр сугыш бәетләренең кайберләрен «турыдан-туры бәет традицияләренә таянып язылган хроника дияргә мөмкин»[56] дип билгеләгән икән, шул ук сыйфатламаны әсирлек бәетләренә карата да әйтергә була бит. Бу очракта татар чыганакларының төп әһәмияте шунда ки, алар – бөтен җәфаны үзләре чиккән татар сугышчылары һәм әсирләре тарафыннан язылган. Ә алман архивларындагы рәсми мәгълүматлар, нинди генә булсалар да, безнең татарларны дошман массасы итеп санаган һәм үзләренең мәкерле мәнфәгатьләрендә кулланырга ниятләгән немецларның карашын чагылдыра.

Мөселман әсирләренең Вюнсдорф лагере турында язылган мәкаләләрне укыганда, урыны-урыны белән аларның авторлары алман пропагандасына бирелеп һәм ияреп киткәндәй тоела. Мөхәммәт Мәһдиев мәкаләсендә, аерым алганда, мондый юллар бар иде: «Вюнсдорф лагере Германиядәге барлык татар әсирләренең мәдәният учагына әверелгән. Монда татарча спектакльләр, концертлар куелган, укыту эше юлга салынган... алар янына Германия галимнәре килеп йөргән... лагерь шулай итеп, кешеләрдә интернационализм хисләре тәрбияләүче учакка әйләнгән... Лагерьда биюгә өйрәтү түгәрәге дә эшләгән... Вюнсдорфтагы татар әсирләренең барысы да бальный танецка өйрәнеп кайта. Апрель аенда Вюнсдорфтагы татар әсирләре якын-тирәдәге бөтен якташларын чакырып, Сабантуй бәйрәме ясыйлар»[57]. Менә бу өзектә әйтелгән «Германиядәге барлык татар әсирләренең мәдәният учагы» дигән фикерне, шулай ук лагерьның интернационализм учагы буларак бәяләнүе – үткәндәге чынбарлыкны чагылдыра дип булмый. Чөнки Вюнсдорфтагы лагерь дошман кулындагы әсирләр лагере булган һәм анда тотылган татарлар һич тә үз

[56] Татар халык иҗаты. Бәетләр..., 1983. – Б. 9.
[57] Мәһдиев М. Герман җире яшел үлән... – Б. 31–32.

ирекләре белән алдынгы Европаның мәдәни казанышлары белән танышырга дип, шулай ук тиктомалдан интернациональлекне өйрәнергә дип бармаганнар, ләбаса. Вюнсдорфтагы бөтен татар әсирләренең «бальный танец»ка өйрәнеп кайтуларына килсәк, ул сугышта катнашкан татарларның барысы да диярлек авыр крестьян хезмәтенә бәйле авыл кешеләре булганлыгын искә алганда, сокланып таң калырлык нәрсә түгел. Һәрхәлдә, әлләниткән биюләр өйрәнеп илгә кайткан ул бичараларның берәрсендә зиннәтле-купшы сарайлардагы «бал»ларда катнашырлык һәм «танец»ларга йөрерлек мөмкинлек-ихтыяҗ булмаганлыгы аермачык билгеле. Үзләре әйткәнчә, чит-ят җирләрдә читлектәге кош хәлендә, тулы билгесезлектә яткан, газиз туган җире, ачлыктан интеккән гаиләсе, туганнары, сөекле сабый балалары һәм хәсрәтле әти-әниләрен бер минутта да исләреннән чыгармаган ул мескеннәрнең башында бию кайгысы булмаган. Гомумән, мондый темалар турында язганда кешеләрне чынбарлык мохитеннән аерып карау ялгыш нәтиҗәләргә китерә. Татар язмышы турында каләм тибрәтергә алынучы татар ул-кызлары бихисап җәбер-җәфалар күргән милләтебезнең тарихи хәтерен һәм үзаңын тирәнтен аңларга тиеш.

Беренче Бөтендөнья сугышы чорындагы татар әсирләре турында әле соңгы араларда гына басылган мәкалә эчендә, шул сугышны китереп чыгаручыларның берсе, миллионлаган татарлар тарафыннан ләгънәтләнгән Алмания кайзеры Вилһельмнең фоторәсеме бирелү дә аптыраш тудыра[58]. Юкса, ул гыйфритнең исемен татарлар шул чордагы матбугаттан һәм бәетләрдән укып яхшы белгәннәр. «Сугышка бара Вилһельм үзе, халкы кырылгач канлана күзе» дип яманлаганнар, каргаганнар. «Казан утлары» кебек, бай тарихлы һәм тәҗрибәле милли басма сәхифәләрендә мондый нәрсәләрнең чыгуы бигрәк тә гаҗәпләндерде. Бер караганда, үз заманында Гитлер дәрәҗәсендә сүгелгән һәм ләгънәт укылган кайзерның сурәте бирелгәч, мантыйк буенча баланс һәм, үзенә күрә, гаделлек өчен фронтның бу як тарафтагы император җәнапләренең дә фотосы булырга тиеш кебек иде. Әмма шул ук мәкаләдәге икенче фоторәсемдә дә Германиянең ата идеологларыннан Оппенһайм хәзрәтләренең кыяфәтен күрәбез. Безнең

[58] Гыйләҗев И. Беренче бөтендөнья сугышында Алманиядә... – №2. – Б. 128.

татар укучысына җәһәннәмдәге вилһельм-оппенһаймнарның чырайларын күрү ихтыяҗы бар мени соң, йә?! Юктыр. Бу, әлбәттә, әтисе шул сугышта катнашкан һәм әсирлеккә эләккән[59] «Казан утлары» журналының баш мөхәррире урынбасары Рәфикъ ага Юныска да, шул ук фронтта авыр җәрәхәтләр алып кайткан, әнием ягыннан бабам, һәм дә әтием ягыннан бабамның өч бертуганы: кулы яраланган һәм авыр контузияләнгән абыйсы белән аягын сугышта өздергән бер һәм сәламәтлеге зарарланган икенче энеләренең хатирәләрен күңелләребездә йөрткән без фәкыйрьгә һәм башка күпләр өчен дә немец сурәтләре һич газиз түгел. Ул сугышта катнашкан һәм әсирлек газапларын кичкән кешеләрнең туганнары, балалары һәм оныклары әле дә исән бит. Ул дәһшәтләрдән йөз елга якын вакыт узган булса да, әсирлектә булган аталарына бәйле рәвештә безнең көннәргәчә «Герман» яки «Плин» кушаматлары кулланыла әле[60]. Димәк, хәтер дә яши. Үзебезнең татар авторларына милләттән өстен кыяфәттә язарга бер кем дә хак бирмәгән бит. Һәрхәлдә, Беренче Бөтендөнья сугышында катнашып, мең төрле михнәт күргән, яу кырларында һәлак булган күп санлы каһарман милләттәшләребез рухлары алдындагы җаваплылык һәм аларның үксез калган балаларына хөрмәт хисе булырга тиеш.

***

Инде бәетләр дәфтәренә килик. Татар солдаты Мифтахетдин Габделгалим улының күләме 74 биттән торган дәфтәрендә күпчелек урынны бәетләр биләп тора. Анда башка төр мәгълүмат: көндәлек язмалары, адреслар, догалар һ.б. да теркәлгән.

Дәфтәрдә барлыгы дүрт бәет һәм Мөхәммәд пәйгамбәрне мактауга багышлап иҗат ителгән бер мөнәҗәт язылган. Кульязма истәлекнең дефектлары булу сәбәпле, кайбер сүзләрне уку мөмкин түгел. Шулай ук бәетләрнең кайбер юллары шигъри үлчәмнән кыскарак, ә кайберләре исә, киресенчә, озынрак булуы да күзәтелә.

---

[59] Рәфикъ Юныс. Тормышым сәхифәләре // Казан утлары. – 2013. – №3. – Б. 146–147.
[60] Мәрданов Р. Тарихта тибрәлгән Тәбәрле... – Б. 171, 380.

Бәетләрнең беренчесе «Сугыш әхваленнән» дип аталган һәм ул «Кыйссаи Йосыф» әсәренең шигъри калыбында иҗат ителгән. Ул 71 дүртьюллыктан тора. Икенче бәет «Ятимнәр бәете» дип исемләнгән һәм 76 дүртьюллыктан гыйбарәт. Өченчесе – «Плиннәрнең бәете» 81 дүртьюллык күләмендә һәм дүртенчесе – «Сугыш бәете» исеме белән аталганы 46 дүртьюллыкны тәшкил итә. Дүрт бәетнең дә текстлары зур күләмле, бөтенесен бергә кушып исәпләгәндә, алар 274 дүртьюллыктан гыйбарәт була. Эчтәлекләре ягыннан бәетләр бер үк – Беренче бөтендөнья сугышына бәйле.

Әлеге бәетләр татар халык авыз иҗатының борынгыдан килгән бай традицияләре нигезендә язылганнар. Аларның телендә борынгы төрки-татар грамматик үзенчәлекләре байтак. Бу, бигрәк тә, «Кыйссаи Йосыф» әсәренең шигъри үлчәмендәге беренче бәеттә күп. Текстларның бөтенесендә дә «-ай, -әй» рәвешендәге кушымчалар – борынгыдан килгән төрки-татар сөйләм һәм язма теле үрнәге. Галимов дәфтәрендәге бәетләрдә:

Йосыф китабы көе берлә бән көйләем,
Үз хәлемне сезләргә бән сөйләем.
Бу хәсрәтне ничек итеп кичерәем,

– кебек һәм шулай ук «Бәнем эткәм кайтмай!» – диеп, ятим бала йыглайдыр», «Бер Ходайдин мир сораймыз, кабул булмай теләкләр» рәвешендәге язылышларның күп булуы дәфтәр хуҗасының туган төбәге – Әгерҗе ягы татарларының элек һәм хәзер дә нәкъ шулай сөйләшүенә дә бәйле[61].

Бу җыентыктагы бәетләр язылган заманның һәм шартларның тәэсире белән сөйләм телендә кулланылган рус сүзләре дә шактый. Мәсәлән, текстларда бомба, война, войска, граница, кашевар, комната, маневр, наступать, помещик, переводчик, поход, поверка, прогулка, пуля, старший, строй һәм башка рус сүзләре бар. Әсирлек турындагы бәеттә айн, цвай, лос кебек немец сүзләре дә очрый.

---

[61] Тел галимнәре тарафыннан «борынгылык» дип билгеләнгән бу күренешнең тарихы һәм Әгерҗе төбәгендә яшәүче татарларда кулланылышы турында тәфсиллерәк мәгълүматны аерым язган идек (Мәрданов Р. Тарихта тибрәлгән Тәбәрле... – Б. 164–172).

«Плиннәрнең бәете»ндә яманлап, «житлар» сүзе белән телгә алынган бәндәләр бар. Билгеле булуынча, «жид» дип, гадәттә, яһүдләрне атаганнар. Ләкин әсирләргә багышланган бәеттәге «жит» сүзендә, ихтимал, немецлар әсирләр арасыннан билгеләп куйган күзәтеп эшләтүчеләр яки бүтән төр җаваплы кешеләр күздә тотылгандыр. Андый атама бәет текстында «Нимесләргә суктыралар каһәр суккан шул житлар», «Каһәр суккан шул житларны эшкә һич тә йөртмәйләр», «Каһәр суккан кара житлар безгә булды ыстарший» дигән юлларда очрый. Әсир офицерларның еш кына гади торткыннар өстеннән күзәтче итеп куелуы һәм аларның аеруча кансыз һәм вәхшиләрчә котырынулары турында галимнәр дә яза[62].

Бәетләр, гомумән, күмәк иҗат әсәре булганлыктан, бу дәфтәрдәгеләрен дә аерым авторларга нисбәт итү дөрес булып бетмәс. Соңгы бәетнең ахырында «Бу бәеткә мәгълүм итәм – Мифтахетдиндер атым» дигән сүзләр дә, ул текстны дәфтәрнең иясе Мифтахетдин Галимов иҗат иткән дип тәгаенләп әйтергә дәлил була алмый. Чөнки анда Мифтахетдин исеме бәетне язучы һәм иҗат итүче буларак төгәл күрсәтелмәгән. Ә шул текстның аның кулы белән күчерелгәнлеге хак. Нинди дә булса текстны күчереп алучы үзенең исемен дә күрсәтеп, өстәп кую – татар халкының язма традициясенә хас күренеш[63]. Шул сәбәпле Мифтахетдин Галимов дәфтәрендә язылган бәет текстларын шунда исемнәре теркәлгән Мифтахетдин үзе һәм якташлары Бәдретдин, Мулламөхәммәтнең иҗат әсәрләре дип караудан тыелабыз. Бу әсәрләр, һичшиксез, шушы сугышчыларның катнашлыгы белән бүтән иптәшләре тарафыннан бергәләп язылган бәетләр буларак каралырга тиеш дип саныйбыз.

«Плиннәрнең бәете» тәгаен әсирлек вакытында иҗат ителгәнлеге исеменнән үк күренеп тора. Текстындагы «Газиз рамазан аенда плен төшеп без яттык» дигән юлларына һәм 1915 елның

---

[62] Абдрашитов Э. О социальной ностальгии российских военнопленных в I мировой войне // Социологические исследования. – 2006. – №4. – С. 133.

[63] Бу уңайдан безнең әдәбият тарихында кайбер әсәрләр язылган дәфтәрнең иясен аны иҗат иткән автор рәвешендә тәңгәлләштереп хаталану мисаллары барлыгын искәртергә тиешбез.

июлендә әсирлеккә төшүләре турында дәфтәр иясе Мифтахетдин язып куйган мәгълүматка караганда, бу бәет тоткынлыкка эләккәннән соң, озак та үтмичә, языла башлаган дияргә мөмкин. 1915 елның июль ае – һиҗри календарьның рамазан аена тулаем диярлек туры килә. Шулай ук Мифтахетдин дәфтәрендәге «31 июльдә герман җиренә чыктык» дигән һәм әсирлек бәетендәге «Егерме тугызынчы агусда бәет яза башладым» дигән юлларга караганда, әлеге әсәр Германиядә вакытта иҗат ителгән булып аңлашыла.

Дәфтәрдәге иң беренче әсәр сугыш бәете буларак язылса да, аның аерым юллары әсирлек чоры иҗатыннан булуын күрсәтеп тора. Мәсәлән, «Нәҗат кыйлсын бән фәкыйрьне һәм әсирне», «Яшь гомеремдә тоткынлыкта узды гомерем» кебек юллар шуңа дәлил.

«Ятимнәр бәете»нең ахырындагы «Плиндә һаман җатамыз...» дигән сүзләрдән бу бәетнең дә әсирлек чорында чыгарылганлыгы беленә. Ә шул ук тексттагы «Унсигезенче сентябрьдә безләрне сугышка алды» һәм «Әткәй сугышка киткәндә тездән яуган кар иде» дигән юлларның бер-беренә ярашып бетмәве бәетнең күмәк иҗат әсәре икәнлегенә өстәмә дәлил булып тора.

Бу бәетләрдә тасвирланганнарны гомумиләштереп караганда, алар сугышның дәһшәте, яшәү һәм үлем, чиксез сагыш-моң, туган җирне, туган-кардәшләрне сагыну, әсирлек җәфалары, өметсезлек, билгесезлек, кол хезмәте, ачлык, котылу һәм сабырлык теләп Аллага ялвару һәм башкаларны үз эченә ала. Бәетләрдә бу коточкыч сугышның сәбәпчесе итеп «Герман дигән дошман патша михнәт салды безләргә», «Герман алды безнең бик күп калаларны» дип белдерелгән, ә инде сугышка алдырткан «падишаһымызга каршы торып булмай» диелә. Шул ук вакытта бәет авторлары «Кемнәр өчен кан түгәдер безнең башлар?..» дип иңри. Чарасызлыктан, «Ходa кушкач, кан түгелмәй булмай имди» һәм «Хода язгач, һич тә чара юктыр» дип, тәкъдир-язмышка нисбәт ителә. «Безнең монда җөрүемез мөкаддәрдә язылган», «Без плиндә булмас идек, бер Ходайның бойрыгы» дигән сүзләр дә шул ук фикерне куәтли.

Сугыш хәрәкәтләре бәетләрдә күбесенчә гади татар солда-

тының күргәннәре һәм шәхси кичерешләре аша тасвирланган. Мәсәлән,

«Висла суын чыкканда
Күперләрне салдык без.
Австрия дигән батыйльнең
Күп җирләрен алдык без»,

«Висла суын аша чыктык кораб берлән, куып киттек германнарны пахут берлән», «Пулеләр килә сызгырышып германнардан», «Германнар атуыннан һич туктамай», «Без ятамыз акупыда барымыз мылтык берлән», «Яурыпланга утырып очалар бит һавага», «Вайсканың күп җиренә бумба ташлап китәләр», «Безнең берлән бер чокырда күп мөселман», «Без сугышка барамыз мөселманнар җыелышып», «Германия туп атканда солдат бик күп үләдер», «Висла дигән су буенда күп үлгәннәр җаталар», «Герман сугышында калды күп кешенең башлары», «Без сугышкан чакларда германнарны кырамыз», «Герман алган җирләрне урыс кире аладыр», «Астриянның пулесе уза пыж-пыж итеп колактан», «Тупны тартып баралмай безнең атлар», «Пазитсәдә вакытта комда ятып җокладым», «Германнарны күргәчтен, төне-көне атыштык», «Германнар туп аталар, акупларны ваталар», «Эснәрәт килеп төшкәчтен, сөртә мескен каныны», «Көн дә пахут җөримен» рәвешендәге бәет юлларыннан сугыш мәхшәрен азмы-күпме күзалларга мөмкин. Ә «Висла суы тирән икән, буйламадым», «Висла суын чыкканда бәет чыгара башладык», «Бик зур икән Перемышлин калалары», «Австрия җиренә үскән икән карагач», «Германия границәсенә килде безнең башымыз» кебек, аерым географик атамаларның рифма өчен генә искә алынган урыннары да бар. Текстларда Висла елгасының исеме еш очравы бу бәетләрне иҗат итүчеләр күбесенчә, шул елга буендагы бәрелешләрдә катнашканны белдерә.

Сугыш тасвирлары арасында солдатларның үз хәлләре дә бераз чагылган. Мәсәлән, «Ике йөз илле патрун билемездә», «Ике поттан[64] артык нәрсә алубән җөрттем», «Шинель берлән фурашкы киемемез, кышкы көндә суыкта җөргәнемез», «Шинель киеп

[64] *пот* – 16,3 килограммга тиң булган авырлык үлчәү берәмлеге.

пахут чыгам, мылтыкларны күтәреп», «Көне-төне җөрүгә безнең аяклар таладыр», «Германия тубының колактан китмәй тавышы».

Солдатларны һәм әсирләрне иң әрнеткән ачлык газабы бәетләрнең һәммәсендә дә даими искә алынган. «Куып киттек германнарны пахут берлән, ашамаенча-эчмәенчә, ачлык берлән», «Маневр ясап барганда көн дә безнең карын ач», «Кай көннәрдә аш пешә, салмай бер нәрсә, су кебек», «Алты көн ач җөрдек Висла суының буенда». Менә мондый ачлык хәлләре мөселман татар солдатлары өчен икеләтә газапка әверелгән. Ягъни, бәетләрдәге «Кяфернеңдер безем җыйган һәр ашымыз», «Кяфер кулында ризыкларым бетәр микән?», «Урыс суйган хәрам ашны ашап булмай», «Насыйп булып, җыярым микән хәләл ашлар?», «Дуңгыз мае буладыр ашымызда», «Кяфер дигән залим нәрсә аптырата азыкка» дигән кебек, җан әрнеткеч юллар шуны раслый. «Яхшы сүзләр керми безнең ашымызга» дигәндәге «яхшы сүзләр» – ризыкларның хәрам булуын, ягъни мөселманча дога белән суелмаган һәм әзерләнмәгәнлеген белдерә.

Ачлык мәсьәләсенә килгәндә, рус армиясендә ачлыктан үлүчеләрнең саны әсирлектә шул ук сәбәптән үлүчеләргә караганда күбрәк булгандыр дип яза кайбер рус тарихчылары.

Гомумән, Россия халкы һәм андагы мөселманнар өчен бөтенләй мәгънәсез булган бу сугышта катнашырга мәҗбүр булган татар сугышчылары җәбер-золым күрүләрен ашау мәсьәләсендәге кыенлык белән генә чикләмәгәннәр. «Урыс-кяфер кайтармайдыр илемезгә», «Бу кяфернең әмереннән узып булмый», «Кяфер берлән күрәмез көнемезне», «Бүген үлсәк, кайу безне кәфенләсен, җеназа укып кайу безне каберләсен?», «Мәрхүм булгач солдатны урыс күмә», «Мөселманны җирләр өчен сугышта жук хәзерәт», «Сугышта үлгән мәетләргә кабер казылыр ләхетсез».

Үлем белән йөзгә-йөз очрашкан солдатларның да, әсирлек өметсезлегеннән чиктән тыш газапка дучар ителгән татар сугышчыларының да бердәнбер өмете – Аллада. Беренче бәетнең һәр дүртьюллыгында диярлек Аллага ялвару һәм өметләнү сүзләре язылган: «Бер Ходаем үзе нәҗат кыйлсын имди», «Хак Тәгалә үзе гомер бирсен имди», «Кавышырга Хода насыйп итсен имди», «Бер Ходайны йад итәмез телемездә», «Бер Ходаем үзе

түзем бирсен имди» һ.б. «Плиннәрнең бәете»ндә шулай ук «Плин дигән агыр хәсрәт, Ходай үзе коткарсын», «Плин мескен йыгласа, Ходай кыйлсын тиз азат», «Әй, Ходаем! Рәхмәтең киң, хәляс кыйлсаң ни була?!» кебек Аллаһка сыгыну сүзләре байтак. Ятимнәр һәм сугыш бәетләрендә дә «Әткәсез калган ятимнәрне Хода үзе кадерләсен», «Ятимнәргә ярдәм биргел, җан җараткан Ходамыз?!», «Мәхшәр көне күрешүне йыглап сорыйм Ходайдин», «Теләгез сез Аллаһдин», «Хак Тәгалә гомер бирсен, сабыйларның хакына», «Дога кыйлың Аллага?!», «Бер Аллаһым насыйп итсен, илгә кайтып җитәргә» сүзләре бар.

Чиктән тыш сагышлы-моңлы, сагыну сүзләре бәет текстларында тоташ диярлек дәвам итә. Мәсәлән, «Бу хәсрәтне ничек итеп кичерәем?», «Аман булың, бәхил булың, туганнарым», «Күзләремдән яшьләремне тыялмадым», «Сагынмаклык берлән саргаямыз бу көннәрдә», «Йыгламакдин күрмәй ике күзләремез», «Кайтасы килә, сагындыра – түзеп булмай!», «Илемезгә кайтыр микән башларымыз», «Агадыр күземездән канлы яшьләр», «Аяз көнне томан булса, без йыглай дип белеңез», «Туганнарым исемә төшсә, кан-яшь белән йыглата», «Безнең ризык калган микән туган-үскән илләрдә?», «Туганнарым исемә төшә – йөрәк бәгърен өзәдер».

Татар солдатларының бәгырьләрен балалары ятим калуы аеруча телгәләгән. Мифтахетдиннең дәфтәрендәге аерым «Ятимнәр бәете»ннән тыш, бүтән бәетләрнең текстларында да каһәр суккан сугыш аркасында балаларның ятим калуы турында шактый язылган: «Ятим кыйлды безнең бик күп балаларны», «Ятим булып калды инде балаларымыз», «Ятим калды күп кешенең балалары, хәсрәт берлән саргайды аналары», «Ничә мең яшь балалар атасыз ятим калды». «Ятимнәр бәете»ндәге, гүя, балаларның үз исемнәреннән әйтелгән «Әй, әткәем! Тизрәк кайт?!», шулай ук:

«Балаларың ятим калды,
Газиз әткәм, белдеңме?
Без көтәмез, син килмәйсең –
Кара җиргә кердеңме?»

– юллары аеруча тәэсирле.

Ятимнәргә багышланган бәеттә балаларны укытып, белемле

итү мәсьәләсе дә үзәккә куелган. Ягъни, мәгърифәт зур мөмкинлекләргә башлангыч нигез итеп каралган. Түбәндәге юллар шуңа дәлил: «Ятимнәрне җөртегез мәдрәсәгә сабакка», «Ятимнәрне укытсаңыз, дога кыйлырлар сезгә», «Ятимнәрне укытырга – безгә бурыч, туганнар!», «Якты ай тик ялтырарсыз, гыйлем тәхсил кыйлсаңыз!»

«Кыйссаи Йосыф» калыбында иҗат ителгән беренче бәетнең эчтәлегендә дә, урыны-урыны белән, Кол Гали әсәренә аваздаш чалымнар бар. Мисал өчен, төш күрү һәм аны яхшыга юрау турындагы юлларны әйтергә мөмкин. Бәет текстында «төш» сүзе дә «Кыйссаи Йосыф»тагыча «дөш» дип язылган.

«Ятимнәр бәете»ендәге:

«Әй, агалар, агалар!
Безне сугышка алалар.
Без сугышта вафат булсак,
Ятим кала балалар»,

– юллары да борынгы чорга, Каюм Насыйри язуынча, 1552 елда Казанны руслар яулап алгач, имеш, Шаһгали хан елап әйткән:

«Әй, балалар, балалар!
Бездин җылап калалар...»[65] – дигән юлларга аваздаш. Мондый охшашлыклар XX гасыр башында чыгарылган сугыш бәетләренең халык иҗатындагы күп гасырлык бай мираска тыгыз бәйле дәвамчысы икәнлегенә дәлил булып тора.

Мифтахетдин Галимов дәфтәрендә язылган бәетләрдә тәэсирле сүзтезмәләр һәм кызыклы чагыштырулар да аз түгел. Мәсәлән, «Плиннәрнең күз яшенә балык булып йөзәрсең», «Җиргә төшә – дәрья була күздән аккан яшемез», «Без плиндә ятамыз читлектәге кош кебек» рәвешендәге, бер карашка гади генә, әмма шул ук вакытта шагыйранә тасвирлар бар.

Бу урында әсирләрнең үзләрен, чынлап та, читлеккә ябылган кошлар белән тиңләүгә тукталыйк әле. Әсирлек бәетләренең

[65] Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Календарь: 1881 нче елга. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1880. – Б. 35; Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Т. 1. – Казан: Татар. китап нәшр., 1974. – Б. 67; Каюм Насыйри. Әсәрләр. 4 томда. Т. 3 / төз. Х.Мәхмүтов. – Казан: Татар. китап нәшр., 2005. – Б. 172.

кайберләрендә «Әгәр читлектә кош булса, чыгарып җибәрегез аны» дигән юллар очрый. Моның Икенче бөтендөнья сугышы вакытындагы турыдан-туры чагылышы мисалын элегрәк язганыбыз булды. Ягъни, әтиемнең бертуган абыйсы Салихҗан ага: «Моннан котылсам, үз илемә кайтсам, Алла боерса, читлектәге кошларның бикләрен ачып азат итәр идем», – дия торган булган иң кыен чакларында. Исән калып туган илгә кайткач, ара-тирә Ижевск шәһәренә барганда, чынлап та, базардагы кош сатучылардан сатып алып, читлекләрен ачып очырткан[66].

Мифтахетдин дәфтәрендәге әсирлеккә багышланган бәеттә ачлык һәм немецларның кыйнаулары, башка төрле газап-җәфалар, сугыш хәлләре бергә үрелеп тасвирланган. Мәсәлән, ачлык һәм ашауның начар булуы бу юллардан ачык күренә: «Аш аз бирә, плин туймай – кашеварлар урлап ашайлар», «Безгә ашаткан ашы – сасы итле балыклар», «Көн аралаш пешерә сасып беткән балыкны», «Май да салмай, ит тә салмай – плингә пешкән ашы», «Иртә кофе эчкәндә шикәре жук тешләргә», «Плин мескен йыглап йөри ашка интеккән көндә», «Плиннәрнең ашына дуңгыз мае тураган», «Ашамаенча ач йөргәч, якты дөнья караңгы», «Ашларында дуңгыз мае – күңелләрне болгата», «Икмәге жук, карын ач, шикәрсез чәй эчәмез», «Атнасына бер мәртәбә кишердән аш пешерә», «Безгә биргән ашлары эчереп беткән бәрәңге», «Якшәнбә көн бер аш бирә, өзелә безнең җөрәкләр», «Катып беткән, череп беткән ашка салган борчагы»... Гомумән, Беренче бөтендөнья сугышы чорында немецларга әсирлеккә төшүчеләр арасында ачлыктан һәм төрле авырулардан үлүчеләр саны гаять зур булган. Ачлыктан үлү куркынычы әсирләрне качарга мәҗбүр иткән[67]. Бәеттә язылган «Кайсыларымыз качып кала кара урман эчендә» дигән юллардан да, бөтенләй чит-ят илләрдә качарга омтылуның шундый ук сәбәпләрдән булганлыгын фаразларга мөмкин.

Әсирлектәге кыйналу һәм җәберләнүләрне түбәндәге юллар раслый. «Аяк-кулларын бәйләп, ике-өч сәгать торгыза», «Ул ябуга разый түгел, ярадыр сырт җакларын», «Плиннәрне жәлләмәй, резин белән тукмайдыр», «Таяк белән килеп суккач, плин мескен

[66] Мәрданов Р. Читлектәге кошлар кебек // Шәһри Казан. – 2009. – 20 июнь.
[67] Абдрашитов Э. О социальной ностальгии... – С. 131–132.

йыглайдыр», «Итексезгә итек бирмәй, яланаяк йөридер», «Аста жук, өстә жук – бу ниндәен газаплар?!», «Плиннәрне бик кыйнайлар шул эшләгән эшендә», «Җыгып, сугып, эшкә куып, кыскартадыр гомерне», «Нимес килеп сукканда күзгә яшьләрем тула». Шул ук вакытта «Мөселманны бик ярата нимеснең солдатлары» дип язылган сүзләрдә татарларның эшчәнлек, тәртип, пөхтәлек кебек сыйфатлары күздә тотылган булса кирәк.

Бәеттәге «Эшкә куып алып китә плиннәрне памишшик», «Безне эшкә алып барганда як-ягымызда каравыл», «Плиннәрнең йөзе шунгар сары – көне-төне эшләгәч», «Йөз пот төягән арбаны плин мескен тартадыр», «Нимес эшен эшләйдер плин көн дә, кичен дә», «Арба тартмаган плиннәрне камчы белән кыздыра», «Аш аз бирә, эше каты», «Эшкә куып, аш аз бирә – саргайтты ак йөзләрне» дигән юллардан әсирләрнең немец алпавытларында кол урынына һәм «Нимесләр чахаузендин тазартадыр күмерне» дигән юллардан әсирләрнең ташкүмер чыгара торган авыр шахта хезмәтендә кулланылуы аңлашыла.

Авыр хезмәт белән интектерү өстенә, әсирләрнең аякларына агач башмак кигереп тә бик җәфалаганнар. Моңа бәеттәге юллар дәлил: «Плиннәрнең кигәне – агачтин ясаган башмак», «Ул башмакны ясаган койган резинә кебек», «Ул башмакның авырлыгы – бары килер ун кадак»[68], «Агач башмак киеп йөреп аякларым суелды», «Авыр башмакны киеп йөргәч аякларны шештерә».

Татар әсирләренең тормыш-көнкүреш шартларын «Плиннәрне бергә җыеп, мөселманнарны аерды», «Кяферләрдин аергач, мөселманнар куандык», «Иртә торгач плиннәр ыстройга тезелә», «Нимесләр сигнал кычкырткач, чәйгә җыелып барамыз», «Кичке сәгать бишләрдә ашау алып кайтамыз», «Кичке сәгать алтыда павиркәгә торамыз», «Безнең җаткан җиремез җир астында барактыр», «Плиннәрнең жук кадере – комда ятып йоклайдыр», «Плиннәр качмасын диеп, энәле тимерчыбык белән ураган», «Безнең яткан урынымыз ат кәнүшнәй эчендә», «Безнең җаткан кәнүшнәемез көндезләр дә караңгы» дигән юллардан азмы-күпме күзалларга мөмкин.

Шулкадәрле җәбер-җәфаларга дучар иткән дошманнарны

[68] *кадак* – 409,5 граммга тәңгәл килгән авырлык үлчәү берәмлеге.

бәет авторлары, әлбәттә, яманлап сурәтли: «Германнарны сорасаңыз, бигрәк начар халыклар», «Шул нимесләрне белмәдек – икән дуңгыз кабаны», «Симерткән симез дуңгыз кебек, нимесләрнең корсагы».

Мифтахетдин Галимов дәфтәрендәге бәетләрдә сурәтләнгәнчә, бу сугышның бик куркынычлы булуы, фронттагы һәм әсирлектәге ачлык, сагыш, Аллага сыгыну кебек тасвирлар бүтән бәетләрдә һәм солдат көндәлекләрендә, хатларда язылган хәлләргә аваздаш. Галимов дәфтәрендәге бәетләрдә язылганнарга охшаш юллар да бар. Бер үк сугышта иҗат ителгән бәетләр булганлыктан, бу, әлбәттә, табигый күренеш. Башка бәетләрдә дә хәрби терминнар, рус сүзләре мул кулланылган. Фронттагы авыр хәлләр, шул исәптән ачлык турында исә «Күбрәк вакытта тамак ач була», «Безгә икмәк бирелмәгәч, шинель, итек сатабыз», «Өчәр көнләп позициягә ашарга килми иде», «Ике кадак сохари белән җиде тәүлек йөрдек без», «Солдат мескен сугышканда өчәр суткы ашамый», «Бер кадак сохари илән өч-дүрт сутка йөрдек без» рәвешендәге һәм әсирлек чоры турында «Унике көн поход барып, бер сынык икмәк күрмәдек», «Тәүлегенә ярты кадак икмәк белән асрый», «Пленный Германда йөри тәүлек ярым ашамый», «Өч-дүрт тәүлек аш-су эчми, без мескеннәр барабыз», «Плен төшкәч Австриягә өч кич ашамый тордык», «Ашамыйча, гел су белән дүрт-биш көнләп җөрдек без», «Хинзир мае турыйлар бит безнең ашка», «Биш сутка бер ашамаенча яттык», «Җиде кадак сохари берлән уналты көн җөрдек без» дигән юллар күп. Шулай ук әсирлектәге «Землянкада ята-ята бик сагындык илләрне», «Безне пленга алгач, эт урынына җигәләр», «Бәйләп куйса тормас җирдә – без торабыз зинданда», «Германия бигрәк кансыз, ат кебек җигә безне» дигән юллардан көнкүреш шартларының никадәрле газаплы булганлыгы күзаллана. Менә мондый тасвирлар бәетләрдә күп язылган. Фәнни хезмәтенең төп өлешен Германия Чит илләр министрлыгы архивы материалларына нигезләнеп язган Ләйлә Гатауллина белдерүенчә, архив документлары арасында лагерьлардагы әсирләрнең көндәлек тормышларын күзаллрлык мәгълүмат юклыгын исәпкә алганда, бәетләрдә язылган

тасвирларның әһәмиятле булуы үзеннән-үзе аңлашыла[69]. Шунысын махсус искәртик, дистәләгән бәетләрнең берсендә дә тоткыннарның Вюнсдорф лагерендагыча уңай шартларда, тук һәм рәхәт чигеп ятуга тартым бер генә сүз дә очратканыбыз булмады.

Сугыш афәтенең санап бетергесез михнәтләре өстенә, алда әйтелгәнчә, мөселман татар сугышчылары дини һәм милли изелүгә дә дучар булган. Төрле дин һәм милләткә нисбәтле иллешәр-йөзәр кешене (руслар, мөселманнар һәм яһүдләрне) уртак чокырга догасыз-нисез бергә күмү кебек хәлләр татарларны бик әрнеткән. Фронтта сасы балык һәм чергән кәбестә ашап яту, шакшылык, бетләп бетү, окоплардагы тездән пычраклык һ.б. күренешләр татар солдатларының сугыштан язылган хатларында да тасвирланган[70]. Шулай ук әлеге сугыш турында елый-елый, бик рәнҗеп сөйләнгән хатирәләрдән: «Ач идек, аяктагы чабата тишелде, кайберәүләр яланаяк, җиде кешегә бер мылтык, ашарга юк, бетләп беттек, окопларда пычрак, җитмәсә безне – татарларны «гололобый» дип түбәнсетәләр»[71] дигән сүзләрдән дә фронттагы коточкыч хәл күз алдына килә. Бу сугышта мөселман татар хәрбиләренең төрлечә кыерсытылу мисаллары һәм кичергәннәре турында махсус мәкаләләрдән һәм тарихи хезмәтләрдән дә танышырга була[72].

Алдарак, М.Галимов дәфтәрендә язылган бәетләр турында сүз барганда аларның берничә кеше тарафыннан иҗат ителгәнлеге хакында язган идек. Бу уңайдан Беренче бөтендөнья сугышы чорындагы татар бәетләренең күмәк иҗат ителүенә дәлил булырлык бер хатирәне искә алыйк. Хәзерге Башкортстанның Тәтешле районындагы Аксәет авылында яшәгән Нәҗметдин исемле кеше болай искә алган: «Герман сугышында минем белән бергә бер-

---

[69] Гатауллина Л. Религиозно-политическая пропаганда... – С. 6.

[70] Шарангина Н. «Солдаты смотрят на войну как на огромное несчастье»: солдатские письма с фронтов Первой мировой войны // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1998. – №3/4. – С. 177–184.

[71] Мәрданов Р. Тарихта тибрәлгән Тәбәрле... – Б. 164–172.

[72] Исхаков С. Вместе и порознь: тюрки-мусульмане в российской армии в 1914–1918 годы // Татарский мир. – 2004. – №15; Габдрафикова Л., Салихов Р. Военная повседневность... – С. 305–308; История татар: с древнейших времён. В семи томах. Т. VII... – С. 196.

ничә татар һәм башкорт егетләре бар иде. Бу егетләр сугышта күргән авырлыкларыбыз турында бәет яза башладылар. Әз генә буш вакыт булды исә, бәет язарга тотына торганнар иде. Ахырда пленга эләктек, пленда да һаман яза бардылар»[73]. 1983 елгы «Бәетләр» җыентыгында бер үк төрле текстларның төрле төбәкләрдәге төрле кешеләрнең дәфтәрләреннән алып бастырылган булуы да бәетләрнең күмәк иҗат ителеп, таралыш алганлыкларын күрсәтә[74]. Бу мәсьәләдә кайбер бәетләрнең үзләрендә үк «Бу бәетне без яздык, ничә солдат җыелып» дигән юллары игътибарга лаек[75].

[73] Бәетләр..., 1960. – Б. 375; Татар халык иҗаты. Бәетләр..., 1983. – Б. 303.
[74] Татар халык иҗаты. Бәетләр..., 1983. – Б. 302–305.
[75] Әхмәтзакиров Мөхәммәтшакир. Сугыш бәете // Чын мирас. – 2013. – №6. – Б. 101.

*// (6б кәгазь)*

## МӨНӘҖӘТ: СУГЫШ ӘХВАЛЕННӘН

Йосыф китабы көе берлә бән көйләем,
Үз хәлемне сезләргә бән сөйләем.
Бу хәсрәтне ничек итеп кичерәем?
Бер Ходаем үзе нәҗат кыйлсын имди.

Илемезгә кайтыр микән башларымыз,
Калды микән илдә җыяр ашларымыз?
Яшь вакытта ниләр күрмәй башларымыз,
Бер Ходаем үзе гомер кыйлсын имди.

Бисмилла дип укыңызлар бу бәетни,
Кулга алып укыңызлар хатымызни.
Укыганда искә алыңыз атымызни,
Хак Тәгалә үзе нәҗат кыйлсын имди.

[Безнең ө]чен дога кыйлың һәр иртәни –
[Нәҗ]ат кыйлсын бән фәкыйрьне һәм әсирни.
[Догаларны кабу]л кыйлсын һәр вакытни,
«Удгуни әстәҗиб ләкүм» диер имди.

*// (7а кәгазь)* Аман булың, бәхил булың, туганнарым,
Исән җөреп, сау кайтырга дога кыйлың?!
Каршы герман килгән чакта юк хәл[ләрем],
Ходавәндә үзе носрәт бирсен имди.

Безем өчен дога кыйлың намаз саен,
Иртә-кичә искә алың, торган саен?!



*Мифтахетдин Габделгалим улының дәфтәре. 6б кәгазь.*

Сары төште безем монда буын саен.
Бер Ходаем үзе кабул кыйлсын имди.

Кичә-көндез акча берлән табалмадым,
Ак күмәчне һәм гайрене җыялмадым.
Күзләремдән яшьләремне тыялмадым,
Хак Тәгалә сабры җәмил бирсен имди.

Кичә-көндез акадыр күздән яшем,
Бу хәлләргә мөбтәлядер газиз башым.
Каршымда юктыр бәнем карендәшем,
[Мөбтәля]дер бу хәлләргә газиз башым.

*// (7б кәгазь)* Вафат булсак, кемнәр җуар тәнемезне,
Җеназа укып, кемнәр дәфен кыйлыр безне?
Һич күрмәгән хәсрәтләрне башым күрде,
Ялгыз башым бу хәсрәт[кә] төште имди.

Әй, туганнар! Кайтыр идем илебезгә,
Урыс-кяфер ка[йтармайдыр] илемезгә.
Ике йөз илле патрун билемездә,
Бер Ходаем үзе куәт бирсен имди.

Кайта[сы]мыз килә илемезгә, түзеп булмай,
Бу кяфернең әмереннән узып булмай,
Мөкаддәрдә язылганны җуеп булмай,
Хак Тәгалә үзе гомер бирсен имди.

[Житкәч чи]рат, бән хезмәткә куылдым,
[Туган] илемдә калды бәнем туганнарым,
[Башым] күрәчәк белән тик саргайдым,
Ходавәндә сабры җәмил бирсен имди.

*// (8а кәгазь)* Калды бәнем сәгадәтле әтекәем,
Тугма агам һәм карендәшем, әнкәем.

Дәхи калды бер угылым һәм хәлялем,
Кавышырга Хода насыйп итсен имди.

Имди бондан сугышка бән куылдым,
Дөнья рәхәт[ләреннән] бән җуялдым,
Тереклектә тузаннар[га] бән күмелдем,
Рәхим кыйлып, Хода нәҗат кыйлсын имди.

Без үземез вафат булсак чит җирләрдә,
Туганнарым ятим каладыр илләрдә.
Сагынмаклык берлән саргаямыз бу көннәрдә,
Күрешергә Хода насыйп иткәй имди.

Шатлык берлән рузәләрне тоталмадым,
Җәмәгатем тәрбияләп торалмадым,
Туганнарым йөзен күреп туялмадым,
Хак Тәгалә күрешергә кушсын имди.

*// (8б кәгазь)* Илдән чыккач киттек без далаларга,
Җыеп безне озаттылар калаларга.
Имди безләр төштек авыр хәсрәтләргә,
Хак Тәгалә үзе гомер бирсен имди.

Нәчәлникләр солдатларны җыйдылар,
Безне тотып Германиягә кудылар,
Каршы торып сугышырга куштылар,
Падишаһымызга каршы торып булмай имди.

[Каравы]л берлән тултырдылар паләләрни,
Герман алды безнең бик күп калаларни,
Ятим кыйлды безнең бик күп балаларни,
Бер Ходаем үзе рәхим кыйлсын имди.

Ничәләргә җитте микән безнең яшьләр,
Шушы эшкә тартты микән безнең кашлар?

Безем ниләр күрмәй газиз башлар,
Хак Тәгалә үзе сабыр бирсен имди.

*// (9а кәгазь)* Туганнарым, бән сезләрдән киттем җырак,
Хак Тәгалә кыйлды имди безне фирак.
Безнең өчен дога кыйлың һәр көн йыглап?!
Бер Ходаем үзе кабул кыйлсын имди.

Йоклаганда күрдем мин бер дөш имди,
Бер карт күрдем к[үркәм ак сакаллы].
Каршы торып бәңа изге дога кыйлди,
«Тиз заман кавышырсән», – диер имди.

Дәхи күрдем вафат булган әнкәемни,
Укып бирде бәңа дәхи кәлямемни,
Имди әйтәем сезгә тормыш хәлләремни,
Укып, безгә изге дога кыйлың имди?!

Өсләремнән төшермәдем киемемне
Өч көн, дүрт көн табалмадым чирәмене(?),
Кулың берлән юып булмай бу тәкъдир[не],
Хак Тәгалә үзе нәҗат кыйлсын имди.

*// (9б кәгазь)* Приказ булды падишаһдин ки безләргә,
«Озатың, – дип, – солдатларны сугышырга!»
Тамчы-тамчы яшьләр тулды күземезгә,
Хак Тәгалә сабры җәмил бирсен имди.

Хәбәр булгач падишаһдин ки безләргә,
Сары керде безнең нурлы бу йөзләргә.
Саг-сәламәт кайтып, барып ки сезләргә,
Күрешергә Хак Тәгалә кушкай имди.

Бу хәсрәтне күрә-күрә үзләремез,
Сары булды безем нурлы йөзләремез.

Йыгламакдин күрмәй ике күзләремез,
Кадыйрымыз сабры җәмил бирсен имди.

Кардәшләрем, акмасын күз яшеңез,
Китте инде сугышырга бу башымыз,
[Кипте] инде күземездән бу яшемез,
Догаларны мәкъбүл әйләп, безне нәҗат кыйлсын имди.

*// (10а кәгазь)* Ля бүддә, килмәенчә калмас әҗәл,
Үкенечле... Кыйлалмадым изге гамәл.
Бу хезмәтдин котылырга һич юк әмәл,
Хак Тәгалә иман рузи кыйлсын имди.

Ике поттан артык нәрсә а[лубә]н җөрттем,
Акупа казып җир астында бик кү[п] яттым,
Хәер-дога сездән сорап язган хатым,
Иртә-кичә изге гамәл кыйлсам имди.

Висла суы тирән икән, буйламадым,
Бу хәсрәтләр булыр диеп уйламадым.
Хак тәкъдирдә язмыш икән, җыялмадым,
Бондан түбән хифзы сәлим кыйлсын имди.

Әй, Ходаем, агыр кыйлдың хәлләремни,
Сакла имди, безем газиз җаннарымни?!
Ятим булып калды инде балаларымыз,
Кавыштырсын тизлектә, Мәүлям имди.

*// (10б кәгазь)* Висла суын аша чыктык кораб берлән,
Куып киттек германнарны пахут берлән,
Ашамаенча-эчмәенчә, ачлык берлән,
Күргәзмәсен мөэминнәргә, дога имди.

Әй, Ходаем! Күргәзмәсен мөэминнәргә,
Күрмешемез агыр булды ки безләргә,

Туганнарым, дога кыйлың әсирләргә?!
«Удгуни әстәҗиб ләкүм» диер имди.

Кара ыршылы карурманда ятмышымыз,
Кяфернеңдер безем җыйган һәр ашымыз.
Кайтыр микән безем мондан бу башымыз?..
Хак Тәгалә безне хәляс кыйлсын имди.

Сораганым бирсен иде Кадыйр Мәүлям.
Безнең берлән бер чокырда күп мөселман,
Дөнья күреп булмай – шул бик яман.
Хак Тәгалә бер көн нәҗат кыйлсын имди.

*// (11а кәгазь)* Җакты дөнья күрә чыксам акупалардан,
Куркыта безне – җанымызны шул туплардан,
Пуләләр килә сызгырышып германнардан,
Хак Тәгалә үзе рәхмәт итсен имди.

Бу сугышлар бер вакытта бетәр микән,
Кяфер кулында ризыкларым бетәр микән?
Газиз башлар илләргә кайтыр микән?
Бер Ходаем үзе нәҗат кыйлсын имди.

Пазитсәдә акупадан чыгып булмай,
Кайтасы килә, сагындыра – түзеп булмай!
Урыс суйган хәрам ашны ашап булмай,
Хак Тәгалә сабры җәмил бирсен имди.

Пазитсәдә кулымыз җуып булмай,
Алда су бар – аны барып алып булмай,
Германнар атуыннан һич туктамай,
Бер Ходаем сабры җәмил бирсен имди.

*// (11б кәгазь)* Иртә берлән төтен чыга акупалардан,
Курка-курка без җатамыз шул туплардан,

Төтен күрсә, эснәрәт төшә германнардан,
Хак Тәгалә сакласын үзе имди.

Көндез булса җагып булмай һич утларни,
Герман куймай атуыннан шул тупларни,
Акупада үлтерәдер бик күпләрни,
Мөэминнәргә иман рузи кыйлгай имди.

Германнардан куркуымнан җокламадым,
Карау берлән шулардан күз алмадым,
Каравылдан һичбер сәгать өзелмәдем,
Аякларым шунда өшеп бетте инде.

Шинель берлән фурашкы киемемез,
Кышкы көндә суыкта җөргәнемез,
[Хак Тә]галәгә мәгълүмдер күргәнемез,
Зур хәсрәтләр бу җирләрдә күрдек имди.

*// (12а кәгазь)* Укыңызлар ошбу язган хатымызны,
Укып, дога кыйлыңнар, атымызны.
Саг-сәламәт илемезгә кайтуымызны,
Догаңызны кабуллардан күрсен имди.

Аһ итүбән яттым мин акупаларда,
Бу хәсрәтләр китәр микән тиз заманда,
Калды микән ризыкларым ки илләрдә,
Тиз заманнан кайтырга насыйп иткәй имди.

Әй, туганнар! Мөнәҗәтләр башлар идек,
Солдатларның хәл-әхвален фашлар идек,
Тыңлаганның ике күзен яшьләр идек,
Хак Тәгалә сабры җәмил бирсен имди.

Әй, туганнар! Язабыз бер хикәят,
Сугышның зарилыгын һәм шикаять,

Агырлыкын беләсез. Кыйл гыйнайәт,
Аллаһүммә?! Гафур рәхим кыйлсын имди.

*// (12б кәгазь)* Туганнарым, языйм дисәм сезгә сүзем,
Яфрак кебек саргайды бәнем йөзем,
Яшь гомеремдә тоткынлыкта узды гомерем,
Хак Тәгалә сабры җәмил бирсен имди.

Яхшы сүзләр керми безнең ашымызга,
Кайгы-хәсрәт төште безнең башымызга,
Илдән киттек егерме сигез яшемездә,
Әмер булгач, китмәенчә булмас имди.

Кайтыр микән илемезгә башларымыз,
Калды микән илдә җыяр ашларымыз,
Кибәр микән күземездән яшьләремез?
Хак Тәгалә сабры җәмил бирсен имди.

Бик күп яздым, туганнарым, ачигъланмаң?!
Ачуланып, җөрәгемә кайгы салмаң?
[Намаз с]аен безгә дога кыйлмай калмаң?!
Барча шатлык безгә шушы булды имди.

*// (13а кәгазь)* Әй, туганнар! Инде безгә бәхил булың!?
Сырхау булсак, һичкем безне кадерләмәс,
Үләр булсак, һичкем безне кадерләмәс,
Ошбу күлмәк безгә кәфен булыр имди.

Бүген үлсәк, кайу безне кәфенләсен?
Җеназа укып кайу безне каберләсен,
Солдат мәрхүм диеп кем кадерләсен?
Хак Тәгалә бакый иман бирсен имди.

Кяфер берлән күрәмез көнемезне,
Сырхау улсак, кемнәр сорар хәлемезне,

Вафат улсак, кемнәр җуар тәнемезне,
Кемнәр безгә иман тәлкыйн кыйлыр имди?

Бик зур икән Перемышлин калалары,
Ятим калды күп кешенең балалары,
Хәсрәт берлән саргайды аналары,
Хак Тәгалә үзе рәхим кыйлсын имди.

*// (13б кәгазь)* Һәр вакытта каеш безнең билемездә,
Бер Ходайны йад итәмез телемездә.
Җөреп кайтып булыр микән – белмимез[76] дә,
Бер Ходадин дога кыйлып теләң имди?

Чит җирләрдә нәфәкаләрем бетәр микән,
Хода безне бер көн нәҗат итәр микән,
Юкса, гомерем хәсрәт берлән үтәр микән?
Фирак уты бәгыремне ягар имди.

Әй, туганнар! Агадыр күздән яшьләр,
Сугышта вәйран була газиз башлар.
Насыйп булып, җыярым микән хәләл ашлар?
Бер Ходаем үзе насыйп итсен имди.

Иртән торсак бер-беремезне сорашамыз,
Сугышта кергән чакда йыглашамыз,
...штән агыр җәфаларга чыдашамыз,
Бер Ходаем үзе түзем бирсен имди.

*// (14а кәгазь)* Әҗәл йиткәч сугышта кеше үлә,
Мәрхүм булгач, солдатны урыс күмә.
Бу дөньяның агырлыкын солдат күрә,
Хода безгә рәхәт гомер бирсен имди.

---

[76] Бу сүз кулъязмада «билемезгә» рәвешендә язылган. Дөреслектә, «белмимез дә» сүзе язылырга тиеш булгандыр. Шулай ук «илемезгә» сүзе дә рифмага яраша һәм мәгънә ягыннан туры килә.

Нигә кара булды микән безнең кашлар?
Агадыр күземездән канлы яшьләр.
Кемнәр өчен кан түгәдер безнең башлар?..
Ходa кушкач, кан түгелмәй булмай имди.

Кайгы-хәсрәт ашайдыр җөрәгемне,
Хода кабул итмәй һич теләгемне,
Сугышларның хәле өзә үзәгемне,
Һич тә тәкать тоту мөмкин түгел имди.

Афисәрләр торадыр каршымызда,
Һәрвакыт фурашкы башымызда,
Дуңгыз мае буладыр ашымызда,
Бу ашларны Хода[м, кичер], ашыйм(?) имди.

*// (14б кәгазь)* Зур казанда пешәдер безгә ашлар,
Әмер булгач кан түгәдер безнең башлар,
Күземездән кан түгәдер канлы яшьләр,
Хак язганны күрмәенчә булмай имди.

Әҗәл йиткәч, солдатлар көн дә үлә,
Мәрхүм булгач, солдатны урыс күмә.
Хак Тәгалә безнең хәлне үзе белә,
Бер Ходаем үзе саглык бирсен имди.

Пуләләр тисә, тишәдер тәнемезне,
Җир өстенә агызадыр канымызны.
Шул пуләләрдин сакла безем газиз җанны?!
Бер Ходаем үзе гомер бирсен имди.

Бу сугышта саргайды йөзләремез,
Пахут җөрсәк авырта тезләремез,
[Күр]мәз улды дәхи безнең күзләремез,
Бер Ходаем үзе нәҗат кыйлсын имди.

*// (15а кәгазь)* Күргән хәлне язаем бу бәеткә,
Сугышдин баралмадык бер гаеткә.
Әй, туганнар! Алмаңыз сез гаепкә?!
Хода язгач, һич тә чара юктыр имди.

Тупны тартып баралмай безнең атлар.
Безнең өчен дога кыйлсын илдә картлар?!
Бу хәсрәтне бик күп күрде безнең башлар,
Бер Ходаем үзе нәҗат кыйлсын имди.

Җырак җирдә нәфәкаләремез бетәр микән,
Хода безне бер көн хәляс итәр микән,
Юкса, гомерем шулай ук үтәр микән?
Фирак уты бәгыремне ягар имди.

// *(15б кәгазь)* **МӘДХЕ ӘН-НӘБИ**
**САЛЛАЛЛАҺУ ГАЛӘЙҺИ ВӘССӘЛАМ**

Мөфәххире җөмлә җиһансән,
Әй, шәфагать мәгъдәни!
Мәккәдә тугдың, Мәдинә
Эчрә кыйлдың мәскәни.
Васләтеңлә, бән фәкыйри
Әйләгел мәсрүр гани.

Дөшде күңлем, йа, Мөхәммәд!
Җаным арзулар сәни!
Җанлара җан идәр ани,
Җанлара җан аныйдәр.

Маил улдым хуп җәмалеңне
Дөшемдә күрмәгәй.
Рөәйәтеңлә җөмлә
Махсус морада ирмәгәй,
Ул гобаре хакьпайа
Баш игүб, йөз сөрмәгәй.

// *(16а кәгазь)* Дөшде күңлем, йа, Мөхәммәд!
Җаным арзулар сәни!
Гафләт илә үтде гомрем.
Аһ, дәрига! Нидәем?!

Хәдде юк васфынга гаҗиз
Бу пәришани әда,
Зате васфыңны кем әйләр,




*Мифтахетдин Габделгалим улының дәфтәре. 15б кәгазь.*

Чөнки сафаңны җөда?!
Мал-әмлякем юлыңда
Әйләрәм җаным фида.

Дөшде күңлем, йа, Мөхәммәд!
Җаным арзулар сәни!
Җанлара җан идәр ани,
Җанлара җан аныйдәр.

Җәүремә гыйсьян илә кәндем,
Шәэнеңгә дөшән кабул,
*// (16б кәгазь)* Бер шәфагатьдер – риҗамыз,
Хәзрәтеңнән, йа, Расүл!
Рәдде идеб, кабугынга,
Итмәйә, солтаным мәлүл?!

Дөшде күңлем, йа, Мөхәммәд!
Җаным арзулар сәни!
Гафләт илә үтте гомрем.
Аһ, дәрига! Нидәем?!

Чөн диенелмеш шаэнеңгә
«Ләүләк, ләүләк!» Йа, Хәбиб!
Фил-хакыйкатьдер, мәдхеңгә
Лаекдыр бу гариб.
Дәрдлейем, дәрманә кәлдем.
Сәндин ирүр, йа, табиб!

Дөшде күңлем, йа, Мөхәммәд!
Җаным арзулар сәни!
// (17а кәгазь) Җанлара җан идәр ани,
Җанлара җан аныйдәр.

Әнбийаләр хатиме сән,
Йа, Мөхәммәд Мостафа!
Нуре вәҗһең бер нур илә
Булды галимләр сафа!

Эстәйән колларың ирүр
Кабугында мөшфика.

Дөшде күңлем, йа, Мөхәммәд!
Җаным арзулар сәни!
Гафләт илә үтте гомрем.
Аһ, дәрига! Нидәем?!

*// (17б кәгазь)*

## ЯТИМНӘР БӘЕТЕ

Бисмилләһи вә билләһи,
Җитте корбан гаете.
Без әйтәек, сез тыңлагыз,
Сугышларның бәете.

Сугышта җөргән җегетләр
Күрмәй рузә гаетен.
Үзем күрдем сугыш хәлен,
Язам ятим бәете.

Бу сугышның хәсрәтеннән
Китмәй эченнән ярасы.
Әй, кардәшләр! Сез алыңыз
Ятим калган баланы?!

Сугышта бер җегет күрдем,
Төшендә күргән атасын.
Әҗәл сулышын алган,
Җәлләп җылай баласын.

Мөселманны җирләр өчен
Сугышта җук хәз(е)рәт.
Күп балалар ятим калды –
Нидәй авыр хәс(е)рәт.

Ятим калган баланы
Каннар ала күзени.



*Мифтахетдин Габделгалим улының дәфтәре. 17б кәгазь.*

Ятимне кем хур күргән –
Күрмәс оҗмах йөзени.

Ятим калган – хур булган,
Үсеп җиткән – зур булган.
Газиз әткәсе булмагач,
Ике күзе кан булган.

Әткәсез ятим балага
Бай баласы хан булыр.
Әткәлеләр кием кисә,
Ятим бәгъре кан булыр.

*// (18а кәгазь)* Германнар куана микән,
Урыс солдатын үтерсә.
Әнкәсенә бир сабырлык,
«Әткәем...» – дип сораса.

Дәүләтеңез артык булыр,
Таң иртәли торсаңыз.
Шәһид савабын табарсыз,
Ятим хәлен сорсаңыз.

Пәйгамбәрдәй, әүлиядай
Үткән Локман хәкимне.
Әй, өммәтләр! Җуатыңыз
Илдә калган ятимне?!

Ятим бала җабык була,
Илдә күрсәң, танырсыз.
Ятимнәрне хур күрсәңез,
Җәһәннәмдә җанарсыз.

Әткәем диеп уйлайдыр
Сезнең сөйгән углыңыз.

Ятим сез тәрбияләсәңез,
Оҗмахта булыр урныңыз.

Әткәсе сугышка киткәч
Йыглап калды балалар.
Ятимнәрне хур күрсәңез,
Язык булыр, аналар!

Бәнем дустым бик авыр
Җатадыр ла сулышта.
Ятимнәрне хур күрсәңез,
Сез булырсыз хурлыкта.

Германия сугышында
Күп адәмнәр үлде.
Ничә мең яшь балалар
Атасыз ятим калды.

*// (18б кәгазь)* Әй, агалар, агалар!
Безне сугышка алалар.
Без сугышта вафат булсак,
Ятим кала балалар.

Германнар атлары
Бар да тимеркүк диләр.
Бәндин калган ятимнәрне
Кем дә куар, «Кит!» диләр.

Без сугышка барамыз
Мөселманнар җыелышып.
Ятим балалар йөридер,
«Әткәй юк...» – дип, йыглашып.

Безгә биргән ашлары
Бер кечкенә табакта.

Ятимнәрне җөртегез
Мәдрәсәгә сабакка!

Көне-төне сугышканда
Каннар тиядер тезгә.
Ятимнәрне укытсаңыз,
Дога кыйлырлар сезгә.

Сугышта үлгән мәетләргә
Кабер казылыр ләхетсез.
Әткәләре сугышта үлгәч,
Балалар кала бәхетсез.

Күп баланы ятим кылды
Бу сугышкан сугышта.
Ятимне тәрбияләгән кеше
Рәхәт кичерер гомерендә.

Герман сугышында калды
Күп кешенең башлары.
Ятим калган балаларның
Кипмәй күзеннән яшьләре.

Угылын-кызын калдырып
Чыгып китә авылдан.
Бөтен дөнья тулган булыр
Ятим калган баладан.

*// (37б кәгазь)* Плиннәрнең ашына
Ничек ...
Ятимнәрнең хакы өчен
Ходай үзе ...

Сугыш бетеп кайтмаса,
Ирләреңезне [көтмәңез].

Башка иргә барсаңыз да,
Ятимнәрне [какмаңыз]?!

Ятим бала көтеп торыр
Бәңа нәрсә әйтер дип.
«Әткәем кая?» – дип сораса,
...[77] кайтыр дип.

Йыглаганда йыглатмагыз,
Ятимнәрне, әнкәсе?!
Әткәем кайчан кайтыр дип,
Көтәр газиз баласы.

Герман дигән дошман падшаһ
Михнәт салды безләргә.
Әткәңезне сез көтмәгез,
Киткән кайтмас җирләргә.

Эснәрәт килеп төшкәчтен,
Сөртә мескен каныны.
«Балам ятим калды» – диеп,
Йыглап, бирде җаныны.

Әткәңезне көтмәгез,
Вафат булган, белеңез!
Вафат булган әткәңезгә
Коръән хәтем кылыңыз?!

Ятимнәрне хур күрерләр
Ятимнәрнең азгыны.
Әй, ятимнәр! Йыгламагыз!
Сезгә Хакның язганы.

---

[77] Кулъязмада бу юлның башындагы берничә сүзе төшеп калган. Ихтимал, «сез әйтегез» яки «сез әйтмәгез» сүзләре булгандыр дип фаразлыйбыз.

Ятимнәрнең атасын
Шул сугышка куганнар.
Ятимнәрне укытырга –
Безгә бурыч, туганнар!

*// (37а кәгазь)* [Әй, ятимнәр!] Йыгламагыз,
Бай баласын күрсәңез.
[Якты] ай тик ялтырарсыз
Гыйлем тәхсил кыйлсаңыз!

[К]өндә ике-өч сәгать
Правилкәгә җөримез.
[Кор]ъән-хәдис берлән әйтәм –
Ятим хәлен сораңыз?!

[Әткәле-]әнкәле балалар
Шикәр белән чәй эчәр.
Ятим бала аны күрсә,
Җөрәгенә кан төшәр.

Җомга көнне вәгазь әйтә
Безнең авыл хәзрәте.
Ниндәен кешедә дә булмас,
Ятим бала хәсрәте.

Безләр наступайт иткәчтен,
Герман тубын алдырган.
Падишаһга хезмәт иткәч,
Угылын ятим калдырган.

Әткәңез сәламәт кайтса,
Куанычындин көлеңез!
Ятим калган балаларны
Азрак кызгана белеңез?!

Ятимнәрне кадерләңез,
Ясап куйган курчак тик?!
Безгә пешкән ашлары –
Кара борчак ашы тик.

Висла суы агыза
Үлгән адәм гәүдәсен.
Әткәсез калган ятимнәрне
Хода үзе кадерләсен.

Висла суы агымсу –
Чыккан чакта куркалар.
Ятим мескен чирле булса,
Сез имнәңез, корткалар[78]?!

*// (19а кәгазь)* Без сугыштан чыккан чакта
Урыслар бик аз кала.
Ятим балалар йөридер,
Адашкан тик каз бала.

Әй, ятимнәр! Куркытмагыз
Авылдагы ала атны.
«Әткәем кайта!» – дип куана,
Ятим күрсә солдатны.

Ятимнәр әткәсе
Үлеп кала кайларда.
Ятимнәргә ярдәм кылмас
Кайсы авылда байлар да.

Без сугышкан чакларда
Германнарны кырамыз.
Ятимнәргә ярдәм биргел,
Җан җараткан Ходамыз?!!

---

[78] Кулъязмада: «корткалар, имнәңез».

Ятим бала ташламай
Аягыннан катасын.
Сугыш беткәч кайтыр диеп,
Ятим көтәр атасын.

Унсигезенче сентябрьдә
Безләрне сугышка алды.
Кайсы ирләр үлеп калды –
Хатыннары тол калды.

«Балаларың ятим калды,
Газиз әткәм, белдеңме?
Без көтәмез, син килмәйсең –
Кара җиргә кердеңме?

Әткәм! Сине бик сагынам.
Кайдан эзләп табармын?
Барып Коръән укыр идем,
Якын булса кабереӊ».

Әткәм килсә ашар диеп,
Куйдым икмәк богдайдин[79].
Мәхшәр көне күрешүне
Йыглап сорыйм Ходайдин.

*(19б кәгазь)* «Әй, әткәем, әткәем!» –
Диер идем бәбкәем.
«Әткәм кайда китте микән,
Әйтче, газиз әнкәем?!!»

Без атадин ятим калдык,
Безне бигрәк кагалар.
Әткәм дисә, әткәсе бар –
Ниндәй бәхетле балалар.

---

[79] Кулъязмада: богдаен.

Әткәйдин калган киемнәрне
Җуып алып куймадым.
Әткәемнең нурлы йөзен
Күреп һич тә туймадым.

Кай көннәрдә аш пешә,
Салмай бер нәрсә, су кебек.
Ятимнәрдән шундай бар –
Дивана бала кебек.

Безнең казарма каршында
Фанталлыдан су килә.
Ятим калган мескеннәрне
Җуатып кемнәр сөя?..

Без мәдрәсәгә барганда
Җулсыз җирдән китәмез.
Газиз әткәм кайтыр диеп,
Төне-көне көтәмез.

«Әткәмнең киемнәрен
Китерегез, агалар?!
Әй, әткәем! Тизрәк кайт?!
Безне монда кагалар».

Германнар бер дә яратмай
Русия урысын.
Әнкәй безгә шунгар суга –
Әйтсәк сүзнең дөресен.

Син әткәйне кайтыр диеп,
Төне-көне көтәмез.
Әнкәй безне бик тиргәсә,
Мәдрәсәгә китәмез.

*// (20а кәгазь)* Мәдрәсәдән кайтканда
Укыймыз без «Сәгалүк».
Ранинай кайтканда,
Әткәй, сине сорадык.

Әнкәй безнең хәзерләнә
Икмәк салырга пичкә.
Раниннардан сорашамыз –
Әткәйне белмәй һич тә.

Рәхәтләнеп утыра микән
Падишаһлар тәхетендә?
Кыр казы кебек гөрләшә идек,
Әткәй өйдә вакытында.

Әткәй сугышка киткәндә
Тездән яуган кар иде.
Үз әткәем бар чагында
Ни хәсрәтем бар иде.

Кара урман эчендә
Бүреләр бик улайдыр.
«Бәнем әткәм кайтмай!» – диеп,
Ятим бала йыглайдыр.

Без сабакны алган чакта
Бер-бер битләп аламыз.
Кайда солдат күрдек исә,
Шунда йыглап каламыз.

Раниннар бик кайттылар –
Кулы җук та, аягы җук.
Иптәшемнең кайтты әткәсе,
Бәнем әткәм әлдә җук.

Бән уенга чыгып киткәч
Әнкәм бәңа: «Кер!» – диде.
Раниннардан бән сорадым,
«Синең әткәң үлде!» – диде.

Иртә торып тышка чыксам,
Чыклар төшкән үләнгә.
Минем әткәм сугышта үлде,
Безләр калдык үгәйгә.

*// (20б кәгазь)* Корт та ашай, кош та ашай
Сугыштагы мәетне.
Күрмәгәнгә нәсихәт диеп,
Яздым ошбу бәетне.

Бу бәетне язган чакта
Калтырады каләмем.
Бу бәетне шунгар яздым –
Ятимнәргә сәламем.

Плиндә һаман җатамыз,
Йитде Корбан гаете.
Ачлыктан җук зиһнем бетте,
Ятимнәр бәете.

Ир хезмәтен эшләйдер –
Бик жәлләймен әнкәмне.
«Яхшы җирләп куйдыңмы
Бәнем газиз әткәмне?»

Карчыга килеп алганга,
Үрдәк калган бәпкәсез.
Герман сугыш башлаганга
Күп балалар калды әткәсез.

Әткәсезләр үбәдер
Әнкәсенең ияген.
Тапсам, җыеп күмәр идем,
Әткәемнең сөяген.

*// (21а кәгазь)*

## ПЛИННӘРНЕҢ БӘЕТЕ

Бисмилләһи вә билләһи,
Җитте корбан гаете.
Без укыек, сез тыңлагыз,
Ошбу плин бәете.

Муенына марка тагып
Плиннәр аш ташыйлар.
Аш аз бирә, плин туймай –
Кашеварлар урлап ашайлар.

Германия афисәрләре
Кылычларын кайрыйдыр.
Урлаган кешене тотсалар,
Кулларын артка бәйлидер.

Безгә ашаткан ашы
Сасы итле балыклар.
Германнарны сорасаңыз,
Бигрәк начар халыклар.

Гаепле булган кешене
Караңгы кумнытага кергезә.
Аяк-кулларын бәйләп,
Ике-өч сәгать торгыза.

Ике сәгать торгачтын,
Чишәдер аякларын.



*Мифтахетдин Габделгалим улының дәфтәре. 21а кәгазь.*

Ул ябуга разый түгел,
Ярадыр сырт җакларын.

Плин нәрсәсе җугалса,
Эзләп таба немесләр.
Юлдашының нәрсәсен урлап
Бәйләнүче урыслар.

Көн аралаш пешерә
Сасып беткән балыкны.
Мөселманнар урлашмай,
Урлашучы урыс халкы.

*// (21б кәгазь)* Бик килешсез, бик ямьсез
Немесләрнең атлары.
Мөселманны бик ярата
Немеснең солдатлары.

Җизләр белән җалтыраткан
Немесләрнең шапкасы.
Май да салмай, ит тә салмай
Плингә пешкән ашы.

Рәхәтләнеп җөреп булмай,
Плиннәргә тар ишек.
Эшкә куып алып китә
Плиннәрне памишшик.

Иртә кофе эчкәндә
Шикәре җук тешләргә.
«Памишшик яхшы ашата» – дип,
Плин китә эшләргә.

Таяк белән килеп суккач,
Плин мескен йыглайдыр.

Итексезгә итек бирмәй,
Яланаяк йөридер.

Германнар аш өләшкәндә
Бармакларын кергезә.
Һәр көндә өч-дүрт сәгать
Правилкәгә йөргезә.

Нимесләрнең фурәшкәсе
Җалтыраган беризин.
Аю өрәткән урыс кебек,
Кулларында эризин.

Егерме тугызынчы агусда
Бәет яза башладым.
Герман плин алгачтын,
Туган илне ташладым.

Иртә торып тышка чыксам,
Агач башы шеш кебек.
Без плиндә ятамыз
Читлектәге кош кебек.

*// (22а кәгазь)* Германнар туп аталар,
Акупларны ваталар.
Кемнең газиз балалары
Плин төшеп җаталар.

Машиналар кычкыра,
Чуен җулы буенда.
Плин мескен йыглап йөри
Ашка интеккән көндә.

Герман дошманның тубы
Бигрәк каты төшә икән.

Солдат мескен чыдай алмай,
Шунгар плин төшә икән.

Плин чыгып киткәчтен
Каршы алды казаклар.
Аста җук, өстә җук –
Бу ниндәен газаплар?!

Бер тын кофе эчкәчтән,
Плин мескен торадыр.
Битен җуып кофе эчкәч,
Плацларга чыгадыр.

Плацларга чыккачтан,
Ыструйда торамыз.
Нимес кычкырып җибәрсә,
Бик куркышып торамыз.

Плиннәрнең ашына
Дуңгыз мае тураган.
Плиннәр качмасын диеп,
Энәле тимерчыбык белән ураган.

Исерткечне хәрам диләр,
Мөселманнар, эчмәгез!
Дуслар сезгә нәсихәтем:
Плин һич тә төшмәгез!

Безнең җаткан казарманың
Такталарын каерды.
Плиннәрне бергә җыеп,
Мөселманнарны аерды.

*// (22б кәгазь)* Германнарны күргәчтен,
Төне-көне атыштык.

Газиз рамазан аенда
Плен төшеп без яттык.

Бездин калган киемнәрне
Чүдин-чүгә эленеҙ.
Аяз көнне томан булса,
Без йыглай дип белеңез.

Плиннәрнең күз яшенә
Аккош булып очарсың.
Плин дигән агыр хәсрәт,
Ходай үзе коткарсын.

Плиннәрнең күз яшенә
Балык булып йөзәрсең.
Суткәсенә чирек икмәк,
Ничек итеп түзәрсең.

Казаклар күп киткәчтен,
Ятып коедан су алдык.
Кяферләрдин аергач,
Мөселманнар куандык.

Мөэминнәргә ярдәм биргел,
Җан җараткан Ходамыз.
Кичке сәгать алтыда
Павиркәгә торамыз.

Кичке сәгать бишләрдә
Ашау алып кайтамыз.
Мөселманнар җыелышып,
Шаулап тәкбир әйтәмез.

Германнар аш өләшә,
Ашларында бәрәңге.

Ашамаенча ач йөргәч,
Якты дөнья караңгы.

Безнең җаткан җиремез
Җир астында барактыр.
Плин төшкән кешеләрнең
Эшләре бик хараптыр.

*// (23а кәгазь)* Кофе белән бәрәңге –
Безнең ашаган ашымыз.
Плиндә бик михнәт күрә
Безнең газиз башымыз.

Туганнарым исемә төшсә,
Кан-яшь белән йыглата.
Ашларында дуңгыз мае –
Күңелләрне болгата.

Безнең яткан урынымыз
Кара туфрак эчендә.
Акупада җаткан вакытым
Куркытадыр төшемдә.

Германнар аш биргәндә
Мискәләрең тулсайде.
Күп михнәтләр күрде башлар,
Соңдин рәхәт булсайде.

Безнең турда машина,
Искән җил тик бара ул.
Безне эшкә алып барганда
Як-ягымызда каравыл.

Нимесләр сигнал кычкырткач,
Чәйгә җыелып барамыз.

Туганнарым! Сагынсаңыз,
Айга чыгып караңыз!

Чәйне алып кайткачтан,
Баракларга керәмез.
Икмәге җук, карын ач,
Шикәрсез чәй эчәмез.

Германнар аш өләшкәндә
Ашы безгә җитмәде.
Рамазан шәриф рузәләрен
Ходай насыйп итмәде.

Туган-үскән илләремезне
Безләр киттек бит ташлап.
Плиннәрнең кигәне –
Агачтин ясаган башмак.

*// (23б кәгазь)* Плиннәрнең йөзе шунгар сары –
Көне-төне эшләгәч.
Агач башмак шунгар авыр –
Бер нәрсәсез эшләгәч.

Без сугышкан җирләрдә
Бик күп җатадыр үлек.
Ул башмакны ясаган
Койган резинә кебек.

Ул башмакның авырлыгы –
Бары килер ун кадак.
Плин мескен йыгласа,
Ходай кыйлсын тиз азат.

Без плингә төшкәчтен,
Нимесләр күп җыелды.

Агач башмак киеп йөреп
Аякларым суелды.

Раниннарның перевязкәсен
Көн дә җыеп чиштерә.
Авыр башмакны киеп йөргәч
Аякларны шештерә.

Нимес телен һич белмәймез,
«Лос, лос!» – диеп акыра.
Аякларны бик авырттыра,
Һич йөрмәймез такырда.

Ул башмакны кигезеп,
Җибәрәләр эшләргә.
Эштән кайткач аш бирәләр,
Икмәге җук тешләргә.

Төнлә җоклап җатканда
Нимес тора каршымда.
Бу бәетне яза-яза
Уй да бетте башымда.

Пазитсәдә вакытта
Комда ятып җокладым.
«Плин – яман», – дигәннең
Нәсихәтен тотмадым.

*// (24а кәгазь)* Аю баласы кебек
Нимесләрдә бар атлар.
Нимесләргә суктыралар
Каһәр суккан шул житлар.

Нимесләрнең бакчасына
Плиннәрне кертмәйләр.

Каһәр суккан шул житларны
Эшкә һич тә йөртмәйләр.

Плиннәрнең жук кадере –
Комда ятып йоклайдыр.
Плиннәрне жәлләмәй,
Резин белән тукмайдыр.

Плиннәйдә шундай да бар –
Тегүченең остасы.
Каһәр суккан кара житлар
Безгә булды ыстарший.

Безгә дигән хатыңызны
Почтага илтеп салыңыз.
Әй, кардәшләр, жит күрсәңез,
Сугып җанын алыңыз?!

Ниместә җаткан плиннәр
Илен искә төшерә.
Атнасына бер мәртәбә
Кишердән аш пешерә.

Кайда барсаң, плиннең
Хәсрәтләре артадыр.
Йөз пот төягән арбаны
Плин мескен тартадыр.

Иртә торгач плиннәр
Ыстройга тезелә.
Үткән рәхәт искә төшсә,
Ач үзәкләр өзелә.

Нимес эшен эшләйдер
Плин көн дә, кичен дә.

Безнең яткан урынымыз
Ат кәнүшнәй эчендә.

*// (24б кәгазь)* Плиннәрне бик кыйнайлар
Шул эшләгән эшендә.
Кайсыларымыз качып кала
Кара урман эчендә.

Безгә биргән ашлары
Эчереп беткән бәрәңге.
Безнең җаткан кәнүшнәемез
Көндезләр дә караңгы.

Нимесләрнең чанасы
Бөгелмәгән табаны.
Шул нимесләрне белмәдек –
Икән дуңгыз кабаны.

Бер Ходайдин мир сораймыз,
Кабул булмай теләкләр.
Якшәнбә көн бер аш бирә,
Өзелә безнең җөрәкләр.

Прагулкәгә җөргәндә
«Лос, лос!» – диеп куадыр.
Таман салкын су белән
Плин күлмәк җуадыр.

Арба илән бәрәңге
Плиннәргә тарттыра.
Арба тартмаган плиннәрне
Камчы белән кыздыра.

Памишшиккә эшләгәндә
Агач башмак кигерәдер.

Аш аз бирә, эше каты,
Плин кайтып киләдер.

«Ай-субай» дип санайдыр
Пубиркәдә безләрне.
Эшкә куып, аш аз бирә –
Саргайтты ак йөзләрне.

Нимесләр чахаузендин
Тазартадыр күмерне.
Җыгып, сугып, эшкә куып,
Кыскартадыр гомерне.

*// (25а кәгазь)* Нимес килеп сукканда
Күзгә яшьләрем тула.
Әй, Ходаем! Рәхмәтең киң,
Хәляс кыйлсаң ни була?!

Чахаузда эшләгәндә
Буяламын күмергә.
«Лос, лос!» дигән нимес тавышын
Онытмамын гомергә.

Нимесләрнең атларының
Кыска икән койрыгы.
Без плиндә булмас идек,
Бер Ходайның бойрыгы.

Катып беткән, череп беткән
Ашка салган борчагы.
Симерткән симез дуңгыз кебек,
Нимесләрнең корсагы.

Плиннәрне җөргезә
Каты искән җилләрдә.

Безнең ризык калган микән
Туган-үскән илләрдә?..

Кызыл сукна бәйләгән
Пираватчик кулына.
Карай-карай күзләр талды
Русия җулына.

Без нимескә тоткын булдык,
Бик бәхетсез баламыз.
Бер чиреге егерме тиен –
Икмәк сатып аламыз.

Сандугачның аласы
Очып куна богдайга.
Плин төшмәгән кешеләр,
Шөкер итеңез Ходайга[80]!

Нимес дигән, усал дигән,
Жит, әләкче дигән.
*// (25б кәгазь)* Безнең куанычлы көннәр
Кая узып китте икән?

Безләр плиндә ятканда
Укыдык Корбан гаетен.
Ошбу җирдә тәмам кыйлдым
Сезгә плин бәетен.

---

[80] Кулъязмада: Аллага. Ләкин «богдайга» сүзенә «Ходай» сүзе рифмадаш булганлыгы аңлашыла. Бу очрак бәетне дәфтәргә язучының техник хатасы гына дип исәпләнергә тиеш.

*// (26б кәгазь)* **[СУГЫШ БӘЕТЕ]**

Бисмилләһи вә билләһи
Җитте корбан гаете.
Без әйтәек, сез тыңлаңыз,
Бездә сугыш бәете.

Козловкадан чыкканда
Вульнай киемне ташладык.
Висла суын чыкканда
Бәет чыгара башладык.

Висла суын чыкканда
Күперләрне салдык без.
Австрия дигән батыйльнең
Күп җирләрен алдык без.

Безне рус ала дип,
Күп шәһәрләрен җандырган.
...[81]

Австрия җиренә
Үскән икән карагач.
Манебр ясап барганда
Көн дә безнең карын ач.

Австрия җирләре
Ач[ык]лык та сад икән.

[81] Монда булырга тиешле шигъри икеюллык дәфтәрдә язылмаган.



*Мифтахетдин Габделгалим улының дәфтәре. 26б кәгазь.*

*// (27а кәгазь)* Безнең болай җөрүләре
Җөрәк майларын сыза икән.

Иртә торып бит җуам,
Бит җугач битне сөртәм.
Чит илләрдә җөри-җөри,
Гомерем заигъ уздырам.

Висла суы агымсу,
Агымсуда бит җуам.
Туганнарым исемә төшә,
Чүгәләп утырып хәл җыям.

Иртә торып тышка чыксам,
Карыйм килгән җулыма.
Әткәй, әнкәй, туганнарым!
Сезне язам хатыма.

Без ятамыз акупыда
Барымыз мылтык берлән.
Сездән хәбәр сорашамыз,
Туганнарым, хат берлән.

*// (27б кәгазь)* Германия границәсенә
Килде безнең башымыз.
Җиргә төшә – дәрья була
Күздән аккан яшемез.

Германия безнең җиргә
Акупалар казыган.
Безнең монда җөрүемез
Мөкаддәрдә язылган.

Алты көн ач җөрдек
Висла суының буенда.

Җокларга җатсам җокы килмәй,
Туганнарым уемда.

Аягымдагы итегем
Аяз көнне кысадыр.
Туганнарым исемә төшә –
Йөрәк бәгърен өзәдер.

Висла дигән агымсу
Ага икән әйләнеп.
Әткәй, әнкәй! Дога кыйлыңыз,
Тиз кайтсын дип балаңыз.

Висла дигән су буе,
Ике ягы карагач.
Әткәй, әнкәй, туганнарым!
Һич онтылмай(?) карагач.

*// (28а кәгазь)* Висла дигән су буе
Ике җагы ком икән.
Кем йөзенә карасаң,
Үз туганың җук икән.

Висла дигән су өстендә
Парахутлар күп икән.
Бу кяфернең кулында
Безнең ризык күп икән.

Без җөримез илләрдә,
Гер[ма]ния дигән җирләрдә.
Әткәй, әнкәй! Дога кыйлың,
Безгә җомга көннәрдә?!

Без барамыз илләргә,
Германия дигән җирләргә.

Безнең башлар кайтыр микән
Туган-үскән илләргә?

Германиягә без барамыз,
Каршы нимескә таралып.
*// (28б кәгазь)* Алла язса, бер кайтырмыз,
Туган илгә шатланып.

Көн дә пахут йөрүе
Кыен икән пихутка.
Кяфер дигән залим нәрсә
Аптырата азыкка.

Иртә торсам, сигнал уйный,
Чыкма солдат җулга дип.
Әткәй, әнкәй! Дога кыйлың,
Исән кайтсын угылым дип.

Бәндин калган киемнәрне
Җомгаларга киеңез.
Бәнем калган угылымны
Бәнем кебек сөеңез.

Әткәй, әнкәй, туганнарым!
Теләгез сез Аллаһдин.
Безнең башлар исән кайтсын
Ошбу җөргән вайнадин.

Без җөримез вайнада
Акупаларның буенда.
Безнең башлар дивана була
Ошбу җөргән сугышта.

*// (29а кәгазь)* Өстемездән туп атыла,
Кайда төшеп ватыла.

Хак Тәгаләгомер бирсен,
Сабыйларның хакына.

Яурыпланга утырып
Очалар бит һавага.
Мөселманнар! Барчамыз
Тәүбә итик аларга.

Яурыплан белән очып,
Кайтып җавит итәләр.
Вайсканың күп җиренә
Бумба[82] ташлап китәләр.

Кыр казлары сайрашадыр
Килергә вакыт җитә дип.
Туган илгә без кайтырбыз
Германия кире китә [дип].

Мин бәйлимен каешларым
Пазитсәгә китәргә.
Бер Аллаһым насыйп итсен,
Илгә кайтып җитәргә.

Көн дә пахут җөримен дип,
Киемнәремне чылатам.
Аллаһым язса, кайтырмын дип,
Күңелләремне җуатам.

Германия туп атканда
Солдат бик күп үләдер.
Ир-җегетнең газиз башы,
Ни күрсә дә, түзәдер.

Бу хат[ымны] яз[ганда]
Бармакларым таладыр.

[82] Кулъязмада: пумпа.

*// (29б кәгазь)* Герман алган җирләрне
Урыс кире аладыр.

Әнкәйләрем! Сезгә әйтәм,
Эчемә ут җакмагыз.
Уйнап-көлеп барган чакта
Минем баламны какмагыз?!

Шинель киеп, каеш бәйләп,
Пахут чыгып китәмен.
Сез мөбарәк хәзрәтләрдин
Фатиха өмет итәмен.

Мескен солдат башларына
Бигрәк мылтык аталар.
...[83]

Висла суы буеның
Сары икән комнары.
Германия тубының
Колактан китмәй тавышы.

... гурт крипеченә
Германнар туп аталар.
Висла дигән су буенда
Күп үлгәннәр җаталар.

Шинель киеп пахут чыгам,
Мылтыкларны күтәреп.
Раниннарны ташыйлар
Җилкәләренә күтәреп.

Кайда барсаң, шунда җата,
Каннары ага аяктан.

[83] Монда булырга тиешле шигъри икеюллык дәфтәрдә язылмаган.

Астриянның пулесе уза
Пыж-пыж итеп колактан.

// *(30а кәгазь)* Көне-төне җөрүгә
Безнең аяклар таладыр.
Безем халык астриянны
Плингә күп аладыр.

Таң әтәче кычкырса,
Урыныңыздан торыңыз.
Иртәге намазларын укып,
Хәер-дога кыйлыңыз?!

Газиз күңелләр уйлана
Өйдә калган балага.
Тизрәк мирләр булсын диеп,
Дога кыйлың Аллага?!

Талчыкканга баралмайдыр,
Аягым бата, алалмыйм.
Бу бәеткә мәгълүм итәм –
Мифтахетдиндер атым.

Бу хат бармакымыздин
Үтенәмен бит сездин.
Әткәй, әнкәй! Уйлаганга,
Канлы яшь ага күздин.

# КУЛЪЯЗМАНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ

Бәет текстлары язылган җыентык юллы кәгазьле, кечкенә форматтагы куен дәфтәреннән гыйбарәт. Аның зурлыгы 9х15 см, күләме 37 кәгазьне тәшкил итә. Тышлыгы – кара дерматин ябыштырылган юка катыргыдан. Күп укылып һәм, гомумән, күпне кичергәнлектән дәфтәрнең төбе таушалуы сәбәпле, саргылт-кызыл, ак һәм кара җепләр белән берничә мәртәбә тегелгән.

Сакланышы уртачадан начаррак хәлдә. Тышлыгы төп ягыннан дәфтәргә тегелгән, тик яртылаш өлешләре генә сакланган, ягъни ике як чите дә вертикаль рәвештә ертылып юкка чыккан. Дәфтәрнең алгы ягыннан 15 нче кәгазьгә хәтле һәр битенең сул ягы һәм түбәнге тарафлары таушалып җуелган. Төбеннән ертылып төшкән уртадагы бер кәгазе соңыннан иң ахырга өстәп тегелгән.

Дәфтәрнең 1а, 17б–30а, 37а–37б кәгазьләрендәге текстлар шәмәхә төстәге кара белән, 6а–17а кәгазьләрдә – яшькелт химик карандаш белән язылган. Арадагы кәгазьләрдә һәм бәетләрнең буш калган урыннарында гади карандаш белән, ә ахырдагы берничә биттә кызыл кара белән теркәлгән аерым язмалар бар.

Җыентыкның хуҗасы элекке Вятка губернасының Алабуга өязендәге Төрдәле авылы кешесе булып, язмалар аның үзе һәм шул ук өяздәге Чөшле (Яңа Аккуҗа) авылы кешеләренең кулы белән теркәлгәнлеге турында кереш мәкаләбездә әйтеп үткән идек. Дәфтәрнең 1а кәгазендә аның иясе Төрдәле авылының Мифтахетдин Габделгалим улы булуы һәм аның герман әсирлегендә 1915 елда язылганлыгы искәртелгән.

Дәфтәрнең 6а кәгазендә «Мөнәҗәт: Сугыш әхваленнән. Тәхрикел-каләм Бәдретдин Баһаветдин әфәнде. Карьяи Чөшле» дип язылган. Ягъни, монысы Чөшле авылы кешесе тарафыннан



*Мифтахетдин Габделгалим улының дәфтәре. 6а кәгазь.*

теркәлгән. Җыентыкның 6б–15а кәгазьләрендә борынгы Болгар чоры әдибе, мәшһүр Кол Гали иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» әсәренең шигъри калыбында язылган сугыш бәете. Аның башы (6б кәгазьдә):

Йосыф китабы көе берлә бән көйләем,
Үз хәлемне сезләргә бән сөйләем.

Ахыры (15а кәгазьдә):

Юкса, гомерем шулай ук үтәр микән?
Фирак уты бәгыремне ягар имди.

15б–17а кәгазьләрендә шул ук кеше тарафыннан «Мәдхе ән-нәби саллаллаһу галәйһи вәссәлам» тексты язылган. Аның башы (15б кәгазьдә):

Мөфәххире җөмлә җиһансән,
Әй, шәфагать мәгъдәни!

Ахыры (17а кәгазьдә):

Гафләт илә үтте гомрем.
Аһ, дәрига! Нидәем?!

Бу искиткеч шагыйранә һәм затлы әсәрдәге «Гафләт илә үтте гомрем. Аһ, дәрига! Нидәем?!» юллары татар шагыйре Һибәтулла Салиховның 1851 елда иҗат икән «Тәэссеф» исемле касыйдасендә дә кабатлана.

Җыентыктагы 17б–20б кәгазьләрдә «Ятимнәр бәете» язылган. Ул дәфтәргә Чөшле авылының Мулламөхәммәд кулы белән теркәлгән. Бәетнең башы (17б кәгазьдә):

Бисмилләһи вә билләһи,
Җитте корбан гаете.
Без әйтәек, сез тыңлагыз,
Сугышларның бәете.

Ахыры (20б кәгазьдә):

Әткәсезләр үбәдер
Әнкәсенең ияген.
Тапсам, җыеп күмәр идем,
Әткәемнең сөяген.

Бу бәетнең уртарак өлешеннән аерылган бер бите дәфтәрнең артына тегелгән. Бәет текстының кулъязмада 37а һәм 37б санна-

ры белән билгеләнгән битләрдәге өлеше бу басмада безнең тарафтан 18б һәм 19а кәгазьләр арасына кертелде.

Дәфтәрнең 21а–25б кәгазьләрендә шул ук кул белән «Плиннәрнең бәете» язылган. Аның башы (21а кәгазьдә):

Бисмилләһи вә билләһи,
Җитте корбан гаете.
Без укыек, сез тыңлагыз,
Ошбу плин бәете.

Ахыры (25б кәгазьдә):

Безләр плиндә ятканда
Укыдык Корбан гаетен.
Ошбу җирдә тәмам кыйлдым
Сезгә плин бәетен.

Кулъязма җыентыкның 26б–30а кәгазьләрендә «Сугыш бәете»нең тексты язылган. Дәфтәрдә аның исеме аерым күрсәтелмәсә дә, беренче дүртьюллыгында ул «Сугыш бәете» дип аталган. Бу текстның башы (26б кәгазьдә):

Бисмилләһи вә билләһи
Җитте корбан гаете.
Без әйтәек, сез тыңлаңыз,
Бездә сугыш бәете.

Ахыры (30а кәгазьдә):

Бу хат бармакымыздин
Үтенәмен бит сездин.
Әткәй, әнкәй! Уйлаганга,
Канлы яшь ага күздин.

Бу бәетнең ахырында «...Мифтахетдиндер атым» дип исемен белдерүгә караганда, әлеге текст дәфтәргә иясе тарафыннан язылган дип аңлашыла. Бу дәфтәрнең башка битләрендәге шул елларда һәм соңрак теркәлгән бүтән язмалар да бер үк кул белән язылган булуы да шушы фикерне раслый.

Монда күрсәтелгәннәрдән тыш, дәфтәрнең бүтән битләрендә гарәп хәрефләре белән татарча хронологик язмалар, адреслар, төрле җырларның өзекләре, догалар, каләм уйнату өчен генә язылган хәрефләр-сүзләр, шулай ук рус хәрефләре белән рус телендә адреслар һ.б. язылган.



*Мифтахетдин Габделгалим улының дәфтәре. 36а кәгазь.*

Дәфтәрнең башында һәм ахырында (2а һәм 36а кәгазьләрдә) аның иясе: «Город Елабужский уезд, Вятская губерния, Мушакской волости дербена Турдали Муфтахитдин Габдулгалимов» дип, үз адресын язып куйган. Адреслардан шулай ук мондыйлары да бар: «Донский область, Владимирский станция, деревня Грушовка, Михаил Плиховский» (34а кәгазь), «Уфимский губерна, Бирский өяз, Баллыкатаевский волость, дирбина Бурашес(?), Нурмөхәммәд Мифтахетдинов» (34б кәгазь), «Уфимский губерна и уезда, Фёдоровский волость, дер. Иликовский, Хайрулла Тухватуллин» (36б кәгазь). Адреслары язылган бу кешеләр Мифтахетдин белән бергә әсирлек җәфасын чиккән затлардыр. Шулай ук дәфтәрнең төрле битләрендә Хисмәтулла Сапаев, Миңнәхмәт Сөләйман угылы, Гатауллин Г., Ситдиков Наби, Набиев Мирсает, Хайрулла Гизатуллин, Гыйниятулла дигән кеше исемнәре дә теркәлгән.

Дәфтәрнең бәетләр язылган битләреннән башка, буш урыннарында теркәп куелган җырлар һәм бүтән текстларның кайберләре түбәндәгечә. Мәсәлән, 2б кәгазьдәге мөнәҗәт:

Илаһи! Сән – бәнем Раббым!
Бәнем серем сиңа мәгълүм.
Мин сораган нәрсәләрдин
Мине кыйлмаясән мәхрүм?!

Туганнардин аердылар,
Илләремдин чыгардылар.
[Дә]рьялардин [төшерде]ләр
Рәхим кыл, Тәгалә Аллаһ?!

Шәһәрләргә барып кердем
Айның унбише җиткәчтен.
Кавышуы кыен икән
Чит илләргә киткәчтен.

3б кәгазьдә бу рәвештәге хат башламы язып куелган: «Сез ки, гыйззәтле вә хөрмәтле улып торгучы газиз әткәем хәзрәтләренә, без ки Мифтахетдин угылыңнан бик күп-күп сәлам». Шул ук биттә тагын мондый язулар да бар: «...26-нда өйдән акча

алдым. Дикәбернең 17-ндә хат салдым. Дикәбернең ...ндә хат салдым. [Гыйнва]рның 21-ендә хат салдым. Мартның 9-нда фусилкә сорап. Мартның 18-ендә [хат салдым. Мартның] 25-ндә хат салдым. Мартның 22-ндә өйгә салдым хат». Әлеге мәгълүматлар 1914 елның ахыры һәм 1915 елның башына карый торгандыр.

Дәфтәрнең 4б–5а кәгазьләрендә мондый сүзләр язылган: «Июльнең 15 – килдек Аршаудан уң якка. Июльнең 26 – флин төштек. Июльнең 28-ндә Урдан дигән отделения крефления (укрепление-?) килдек. Июльнең 31 – герман җиренә чыктык, гурытка килдек. [Без]ләр плингә төштек июльдә 26. Германда хат салдык икене: агусның 28, сентябрьнең 27».

25б–26а кәгазьләрдә «Кыйссаи Йосыф» әсәре үлчәмендәге мондый дүртьюллык бар:

Әй, туганнар! Мәгълүм кылыйм хәлләремне,  
Бик күп күрдек германнарның илләрене.  
Һич берни юк германнарның илләрендә,  
Азыклары бәрәңге илән кишер имди.

Бу дүртьюллык әлеге дәфтәрдә язылган бәет текстында юк.

Дәфтәрнең 26а кәгазендә тагын бер хат башламы язылган:

«Һу Аллаһ әл-Бари!  
Сагынмакның хәли.

Сез ки, мөхтәрәм улган әфәндемез Мөфтахетдин җәнабе! Йәнә без ки, Хәйрулладан бик сагынып, гайре мөнтәһани сәламнәремне күндерәм».

35а кәгазьдә мондый язмалар теркәлгән: «1915 җылда 26 июльдә төштек флингә. 1917 – килдек 17 июньдә Туфлергә. 1917 җылда Туфлергә килгәч хат салдым июньнең 25-ндә. Туфлердә ун көн тордык та, аннан киттек вульнай эшкә июньнең 28, шишәмбә көн. Өйдән фусилкә алдым июльнең 8. Хат салдым – 9. Өйдән акча алдым ун сум июльнең 15. Хат алдым июльнең 24. Хат салдым июльнең 29».

Дәфтәр иясенең туган якка кайткач теркәп куйган язмалары да бар. Мәсәлән, 31б кәгазьдә «1920-дә Нәүфилә туды, дикәбернең 21-ндә». Шулай ук төрле битләрдә язылган даталар да күренә: 1928 (7а кәгазьдә), һәм «1929 нчы ел» (21а кәгазьдә). 32б кәгазь-

дә якынча 1930–1940 нчы елларда бүтән бер кеше тарафыннан дүртьюллык җырлар язылган:

Әнә килә уфтамабил –
Төягәннәр чылбырлар.
Безнең аерылганны сизеп
Моңны сайрай былбыллар.

Әнә килә уфтамабил –
Төягәннәр багана.
Кеше җәренә хәйран калып
Йөри торган замана.

Әнә килә уфтамабил –
Төягәннәр сифарат.
Сән саныгасыңмы, яныем?
Бән сагынам ифарат.

Дәфтәр битләренең югары тарафына бер яклап кына сулдан уңга таба тәртиптә куелган пагинациясе бар. Ләкин әлеге саннар дәфтәрнең битләре таркалганнан соң яңадан тегелгәч куелган. Моңа «Ятимнәр бәете»нең үз урыныннан аерылган һәм дәфтәрнең ахырына тегелгән бер бите дәлил булып тора. Чөнки ул бит һәм аннан соңгы икенче бит – икесе дә 1 саны белән билгеләнгәннәр.

Моннан тыш, дәфтәрнең Бәдретдин Баһаветдин улы тарафыннан язылган «Мөнәҗәт: Сугыш әхваленнән» дигән өлешенә уңнан сулга таба һәр битенә саннар куелган. 1–22 нче дип билгеләнгән әлеге битләр кулъязманың 6а, 17а кәгазьләренә туры килә. Шулай ук уңнан сулга таба тәртиптә кәгазь битенең берәр ягына 10 нчы кәгазьгә хәтле 1–10 саннары язылган.

Дәфтәрнең читләре шактый таушалган, шул сәбәптән һәм дымланудан текстлары зарарланган. Моннан тыш, 10а–11а, 18б кәгазьләрдәге текст өсләреннән шәмәхә төстәге химик карандаш белән бозган урыннар бар. Алар бала-чага сызгалавына охшаган. Дәфтәрнең читләре таушалганлыктан, текстны тулысынча уку мөмкин булмаган урыннарны бу басмада күпнокталар белән билгеләдек. Аерым хәрефләре сакланган, нинди сүз язылган булуы

аңлашылган очракларда һәм күчереп язылганда төшеп калган сүзләрне, иҗекләрне квадрат җәяләр эчендә өстәдек. Ә кайбер сүзләрнең дөрес укылышы шик уятканда сүзләр янына түгәрәк җәяләр эчендә сорау билгесен куйдык.

Гомумән, дәфтәрдәге бөтен текстларда да хәреф хаталары (ялгыш язулар, нокталар куелмый калуы, артык язылган хәрефләр яисә кайбер хәрефләрнең элементлары язылып бетмәгән) очраклар бар. Бөтен текстларда да сүзләрне «җ»лаштыру һәм «й»лаштыру күренешләре аралашып барган. Мәсәлән, җөрәгем, җегетләр, җатамыз, җук, җулым, җокы, йыглап, йитде, йиткәч һ.б. Андый очраклар бу басмада текстларның үзләрендәгечә калдырылды. Ә «ң» хәрефе урынына «н» язылган сүзләрне дөресләп (мәсәлән, бәрәңге, дуңгыз, караңгы, киң дип) бирүне кулай күрдек. Соңгы – «Сугыш бәете» текстындагы кайбер сүзләрдә «д» хәрефе урынына «з» язылган сүзләр (солзат, колакзан һ.б.) монда «д» хәрефе белән бирелде.

Югарыда күрсәтелгән үзенчәлекләр һәм кимчелекләр, гомумән, бөтен төр кулъязмаларга да хас. Бу очракта исә, сугыш һәм әсирлектәге гадәттән тыш авыр шартларда язылган дәфтәр булуы исәпкә алынырга тиеш.

# СҮЗЛЕК

*агус* – август
*агыр* – авыр
*«ай-субай»* – бер, ике; немец телендәге ein, zwei (айн, цвай) сүзләреннән
*акупа* – окоп
*Аллаһүммә* – йә, Аллам!
*алубән* – алып
*аман* – иминлек
*ани* – аны
*аныйдәр* – аны итәр
*арзулар* – тели
*астриян* – австриян, австрияле
*атымыз* – исемебез
*афисәр* – офицер
*ачигъланмаң* – ачуланма

*әйләгел мәсрүр гани* – шатлыкка күм
*әйләрәм* – кылырмын
*әлдә* – әле дә
*әнбийаләр хатиме* – пәйгамбәрләрнең ахыргысы

*бакый* – мәңге, мәңгелек
*батыйль* – бозык, кяфер
*бән* – мин
*бәңа* – миңа
*беризин* – брезент
*богдай* – бодай
*бондан* – моннан
*булсайде* – булса иде
*бумба* – бомба

*вайна* – сугыш; рус телендәге «война» сүзе
*вайска* – гаскәр; рус телендәге «войска» сүзе
*васләтеңлә* – бергә кушылып
*васфынга* – күркәм һәм мактаулы сыйфатларыңа

*вульнай* – ирекле; рус телендәге «вольный» сүзе

*гайре мөнтәһани* – чиксез, чиктән тыш
*гариб* – мескен, зәгыйфь
*гафләт* – гамьсезлек, наданлык
*Гафур* – Гафу итүче (Аллаһның күркәм исеме)
*гобаре хакьпайа* – аяк астындагы тузанга
*границә* – чик; рус телендәге «граница» сүзе
*гурыт* – шәһәр; рус телендәге «город» сүзеннән
*гыйлем тәхсил кыйлу* – белем алу, уку
*гыйнайәт* – ярдәм

*дәрдлейем, дәрманә кәлдем* – авыру идем, терелдем
*дәрига* – Ни аяныч! Ни кызганыч! Ни үкенеч!
*дәфен кыйлыр* – җирләр
*дәхи* – тагын
*дербена, дирбина* – авыл; рус телендәге «деревня» сүзеннән
*диенелмеш* – диелгән
*дөш* – төш
*дөшән* – төшкән
*дөшде* – төште

*жәлләп* – кызганып; рус телендәге «жаль» сүзеннән
*жимнастик* – гимнастика

*җавит итә* – күрсәтә, хәбәр бирә; рус телендәге «явить» сүзеннән
*җанлара* – җаннарга
*җәр* – яр, сөекле
*җәүремә* – газаплануыма
*җөда* – аерылган
*җөргезә* – йөртә
*җыяр* – ашар

*заигъ* – әрәм, зая
*зате васфың* – мактаулы сыйфатың
*зирагат* – игенчелек

*игүб* – иеп
*идәр* – итәр
*илән* – белән
*иман тәлкыйн кыйлыр* – руханиның мәетне искә төшерү өчен иман укуы
*имди* – инде
*имнәңез* – дәвалагыз
*истикъбаль* – киләчәк
*иткәй* – итсен
*итмәйә* – итмәче
*ифарат* – ифрат

*йад идәмез* – искә алабыз
*йөз сөрмәгәй* – баш орырга, баш ияргә
*йыглап* – елап

*кабугынга* – капкаңа, ишегеңә
*Кадыйр* – Кодрәтле (Аллаһның күркәм исеме)
*казак* – атлы сугышчы, җайдак
*кайу* – кайсы, кем
*карья* – авыл
*кашевар* – аш пешерүче
*кәлям* – догалар
*кәндем* – үзем
*кәнүшнәй* – ат абзары; рус телендәге «конюшня» сүзеннән
*кәррә* – тапкыр, мәртәбә
*кортка* – карчык
*көллияте асар* – әсәрләр җыентыгы
*крипеч* – ныгытма; рус телендәге «крепость» сүзеннән
*кумныта* – комната, бүлмә
*кушкай* – кушсын
*күргәзмәсен* – күрсәтмәсен
*күрмәгәй* – күрергә
*кыйлдың мәскәне* – яшәдең
*кыйлмаясән* – кылма син

*ләүләк, ләүләк* – Асылы белән хәдискә бәйле булган бу гыйбарәнең тулысы «Ләү ләкә, ләү ләкә вә ма халәкътүл-әфләк» (әгәр син булмасаң, әгәр син булмасаң, барлыкны яратмас идем) рәвешендә Риваять буенча, бу сүзләр Аллаһы Тәгалә тарафыннан Мөхәммәт (с.г.в.) атап әйтелгән.

*лос(los)* – әйдә

*ля бүддә* – әлбәттә, чарасыз, котылгысыз

*маил улдым* – теләдем

*мал-әмляк* – мал-мөлкәт

*манебр* – маневр

*марка (marke)* – номер, тамга

*машина* – монда: паровоз, тимер юл составы

*мәдхеңгә* – мактавыңа

*мәҗрух* – яралы

*мәктүб* – хат

*мәкъбүл әйләп* – кабул итеп

*мәлүл* – гаҗиз, моңлы

*Мәүля* – Хуҗа, Яхшылык итүче (Аллаһның сыйфаты)

*мир* – килешү, солых

*мискә* – тәлинкә; рус телендәге «миска» сүзеннән

*морада ирмәгәй* – максатка ирешергә

*Мостафа* –ягъни сайланган, Мөхәммәт пәйгамбәрнең (с.г.в.) күркәм исеме

*мөбтәля* – дучар

*мөкаддәр* – тәкъдир, Аллаһ тарафыннан билгеләнгән язмыш

*мөфәххире җөмлә җиһан* – бөтен дөнья тарафыннан макталучы

*мөшфика* – шәфкатьле, йомшак күңелле

*намә* – хат

*наступайт иткәчтен* – һөҗүм иткәч

*нәҗат* – котылу

*нәфәка* – Аллаһ тарафыннан билгеләнгән өлеш, ризык

*нәчәлник* – бу текстларда: командир; рус телендәге «начальник» сүзеннән

*нидәем* – нишлим

*ниндәен* – нинди

*носрәт* – ярдәм
*нуре вәҗһең* – йөзең нуры

*ошбу* – бу

*павиркә* – тикшерү; рус телендәге «поверка» сүзеннән
*пазитсә* – позиция
*палә* – басулар, кырлар; рус телендәге «поля» сүзеннән
*памишшик* – алпавыт; рус телендәге «помещик» сүзеннән

*парахут* – пароход
*пахут* – поход
*пәришани әда* – таркау аваз
*перевязкә* – яра бәйләвече; рус телендәге «перевязка» сүзе
*пираватчик* – тәрҗемәче; рус телендәге «переводчик» сүзе
*пихут* – җәяүле гаскәр; рус телендәге «пехота» сүзеннән
*пич* – мич
*правилкә* – тикшерү; рус телендәге «проверка» сүзеннән
*прагулкә* – йөрергә чыгу; рус телендәге «прогулка» сүзе
*приказ* – әмер
*пубиркә* – поверка; тикшерү
*пуле* – пуля

*ранин, ранинай* – яралы; рус телендәге «ранен, раненый» сүзләреннән
*рәдде идеб* – кире кагып
*резинә* – резина
*рижҗа* – үтенеч, теләк
*рөэйәтеңлә* – төштә күреп
*рузә* – ураза
*рузи кыйлсын* – язсын

*сабры җәмил* – күркәм сабырлык
*саг* – сау
*сад* – бакча
*сәгадәт* – бәхетле

*«Сәгалүк»* – тулы атамасы «Һәдиятес-сагълүк» булган дини китап исеме

*сән* – син

*сәнә* – ел

*сәндин ирүр* – синнән ирешә

*сифарат* – сепарат

*сонгый* – ясалма

*соңдин* – соңыннан

*сукна* – постау; рус телендәге «сукно» сүзе

*суткә* – тәүлек; рус телендәге «сутка» сүзе

*тәртип кылынган* – язылган, иҗат ителгән

*тәхрикел-каләм* – каләмне хәрәкәтләндерүче, язучы

*тугдың* – тудың

*тулсайде* – тулса иде

*«удгуни әстәҗиб ләкүм»* – Миңа дога укыгыз, кабул итәчәкмен. Киңрәк мәгънәсе: «Миннән дөнья, ахирәт хаҗәтләрегезне сорагыз – теләкләрегезне кабул итәрмен, җавапсыз калдырмам» (Коръәннең «Мөэмин» сүрәсендәге 60 нчы аять)

*улган* – булган

*улды* – булды

*улсак* – булсак

*уфтамабил* – автомобиль

*үгәй* – үги

*фантал* – краннан яки колонкадан килә торган су; рус телендәге «фонтан» сүзеннән

*фил-хакыйкать* – дөреслектә, чыннан да

*фирак* – аерылу, аерылышу

*флин* – әсир, тоткын; рус телендәге «плен» сүзеннән

*фурашкы, фурәшкә* – фуражка

*фусилкә* – посылка

*Хәбиб* – Аллаһның сөеклесе, Мөхәммәт пәйгамбәрнең (с.г.в.) мактаулы сыйфаты

*хәдде юк* – чиге булмаган
*хәлял* – хатын
*хәляс кыйлсын* – коткарсын
*хәтем кылу* – уку
*хинзир* – дуңгыз
*хифзы сәлим* – иминлек
*Ходавәндә* – Ходай
*хуп җәмаль* – күркәм йөз

*Һу Аллаһ әл-Бари* – Ул, Аллаһ, юктан бар итүче (хат башламнарында еш кулланылган гыйбарә

*чахауз* – шахтадан чыгарылган күмерне эшкәртү урыны; немец телендәге schachthaus (шахтхауз) сүзеннән
*чү* – чөй
*чөн* – чөнки

*шапка* – баш киеме
*шәфагать мәгъдәне* – гөнаһлыларның гаепләре кичерелүгә арадашчылык итүче
*шәэнеңгә* – шаныңа, дәрәҗәңә
*шеш* – нәзек колга
*шишәмбә* – сишәмбе
*шунгар* – шуңа
*шыршы* – чыршы

*эризин* – резина
*эснәрәт* – снаряд
*эстәйән* – теләгән
*эчрә* – эчендә

*ыстаршиий* – җаваплы, башлык; рус телендәге «старший» сүзе
*ыструй* – саф; рус телендәге «строй» сүзе
*якшәнбә* – якшәмбе
*яурыплан* – аэроплан

## РЕЗЮМЕ

Тринадцатое издание серии «Татарская археография» представляет собой публикацию текстов баитов, посвящённых Первой мировой войне. Тексты данных баитов были собраны в рукописной записной книжке, которая вместе со своим владельцем – Мифтахутдином Галимовым (1888 года рождения), пережив тяжёлые условия немецкого плена, возвратилась на Родину, а точнее, в деревню Турдали Елабужского уезда Вятской губернии (ныне Агрызский район Республики Татарстан). Рукописная книжка была обнаружена в 2008 году в сельской мечети (ныне деревня вошла в состав села Крынды).

Скудные записи тетради свидетельствуют о том, что солдат русской армии М.Галимов, принимавший участие в военных действиях близ Варшавы, попал в плен 26 июня 1915 года. Пережив все тяготы плена: голод, избиения, рабский труд и прочие издевательства в лагерях Германии, в 1917 году он вместе с другими был переведён в город Туфлер, что на севере Франции. О времени его возвращения в Россию сведений нет. Согласно поздним записям, в 1920 году М. Галимов уже находился в родном селении.

В тетрадке Мифтахутдина Галимова содержатся тексты четырёх баитов – стихотворных образцов лиро-эпического жанра татарского фольклора. В начале тетради имеется запись о том, что она принадлежит М.Галимову и была начата 10 октября 1915 года в германском плену. Некоторые тексты записаны земляками Галимова – уроженцами деревни Новое Аккузино (ныне Агрызский район РТ). Два текста названы баитами о войне и посвящены ужасам той страшной войны. А один из баитов – «Баит пленных» – повествует о скорбной доле военнопленных. В «Баите сирот» описана несчастная судьба детей фронтовиков, ставших сиротами.

Баиты о войне сочинялись коллективно самими же солдатами

на разных фронтах Первой мировой войны. Уже в 1914 году тексты баитов были опубликованы в г. Казани отдельными изданиями, которые широко распространялись и на передовой линии среди военнослужащих из татар. Книги баитов издавались ежегодно и до 1917 года пережили несколько изданий. В советское время в разных сборниках фольклорных произведений были опубликованы десятки разных вариантов баитов, посвящённых Первой мировой войне. Однако большая часть этих произведений, сохранившихся в тетрадках, записных книжках татарских солдат, а также переписанных другими лицами, ещё не была опубликована. Так, в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан хранятся около двадцати вариантов списков подобных баитов. Предлагаемые читателю в этом издании тексты четырех баитов публикуются впервые.

Во вступительной статье к сборнику дается обзор опубликованных в 1914–1917 годы и позднее книжек и сборников, рукописных вариантов баитов о Первой мировой войне, приводятся сведения о татарских военнопленных тех лет.

В последние десятилетия периодически публикуются материалы, освещающие историю, быт и условия пребывания татарских военнопленных в Германии и Австро-Венгрии. Правда, большая часть публикаций посвящена особым пропагандистским лагерям Вюнсдорфа и Цоссена. По мнению историка И.Гилязова, эти два лагеря представляли собой лишь малую часть территорий, где пребывали плененные татарские солдаты, так как, утверждает учёный, татарские военнопленные содержались, в общей сложности, в 100 лагерях Германии.

При сравнительном изобилии информации о пропагандистских лагерях на фоне малозначительного материала об остальных, получить более полные сведения о лагерях и о самих пленных нам не представляется возможным. В то же время фрагментарно, по крупицам эта информация представлена в различных источниках (письмах, дневниках и баитах), авторами которых являются сами участники и очевидцы войны. Например, факты, описанные в баитах данного сборника, свидетельствуют о положении пленных русской армии, о невыносимых условиях, в которых их содержали: пленные работали круглосуточно в шахтах, их жестоко избивали резиновыми

дубинками, содержали в тяжёлых условиях, очень плохо кормили (супы из гнилой картошки и гороха, отсутствие хлеба, в выходной день кормили лишь один раз), многие ходили без обуви, другим давали тяжёлые деревянные башмаки, пленные ночевали в подвалах на песке или в тёмных конюшнях...

Баиты – письменные свидетельства той страшной войны – являются важными источниками в исследовании трагических страниц Первой мировой войны.

Издание иллюстрировано образцами факсимиле отдельных страниц рукописи.

## «Татар археографиясе» сериясендә чыккан китаплар

Татарстан Милли китапханәсенең «Милли китап» нәшрияты тарафыннан 2008 елда «Татар археографиясе» дип аталган махсус сериядә фәнни-популяр басмалар чыга башлады. Сериянең төп максаты – китапханәнең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган тарихи, әдәби һәм башка төр язма истәлекләрнең текстларын басмага әзерләп нәшер итү аша татар кульязма мирасын пропагандалау.

Басма җыентыкларда кульязма истәлекләрнең текстлары һәм төп чыганакның күчермәсе, фәнни мәкаләләр, кульязмаларның тасвирламалары, искәрмәләр һәм русча резюме бирелә. Сакла081 дәрәҗәсе мөмкинлек биргәндә төп чыганакның күчермәсе – факсимилесе дә бастырыла.

**Мәүла Колый поэмалары:** «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. – 88 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 1 нче китап). **Шул ук.** – Икенче басма. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2011. – 88 б.

Фәнни җыентыкта XVII гасыр татар шагыйре Мәүла Колый иҗат иткән ике поэма тексты, аларның табылу тарихы һәм фәнни әһәмияте турындагы мәкаләләр тупланды. Бу поэмалар хәзергә бердәнбер – 1754 елгы күчермәдә билгеле.

**Түләк китабы:** дастан / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. – 76 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 2 нче китап).

Китапта тирән мәгънәле һәм мавыктыргыч сюжетлы борынгы татар дастанының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган, XIX гасырның беренче яртысында күчерелгән кулъязма тексты һәм аның турындагы мәкаләләр тәкъдим ителә.

**«Кыйссаи Йосыф»** поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. – 92 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 3 нче китап).

Бу китапта борынгы язма әдәбиятыбыз ядкәре – мәшһүр шагыйрь Кол Гали иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган, XVII–XX гасырларга караган 33 берәмлек кулъязма күчермәсенең тасвирламалары тәкъдим ителә.

**Мөхәммәдьяр. «Нуры содур»** поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмалары / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. – 128 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 4 нче китап).

Җыентыкта XVI гасыр татар шагыйре Мөхәммәдьяр иҗат иткән «Нуры содур» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган ике кулъязма нөсхәсенең текстлары басылды. XVIII гасырда күчерелгән кулъязмаларның берсе 1023, ә икенчесе 1165 шигъри юлны тәшкил итә.

Поэманың 1997 елда нәшер ителгән тәнкыйди басмасы белән бу текстлар арасындагы аермалар һәм үзенчәлекләр тәгаенләп күрсәтелде.

**Мәрданов Р.Ф. Китапларда милләт язмышлары...** / Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2010. – 92 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 5 нче китап).

Бу китапка кулъязма истәлекләрне эзләү, туплау һәм өйрәнү эшенә, татар археографиясенең катлаулы мәсьәләләренә багышлап 1991–2006 елларда язылган мәкаләләр тупланды.

**[Мөхәммәтәмин]. Кыйссаи Мансур** / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф.

– Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2010. – 128 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 6 нчы китап).

Китапта мәшһүр суфый Мансур әл-Хәлляҗгә багышланган поэманың Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган ике кулъязма күчермәсе нигезендәге тулы тексты бирелә. Ул 1734 шигъри юлны тәшкил итә.

Мавыктыргыч эчтәлектәге, татар әдәбияты тарихында моңарчы билгеле булмаган бу әсәрнең иҗат ителгән вакыты – XVI гасыр, ә авторы Мөхәммәтәмин дип фаразлана.

**[Фәезханов Хөсәен]. Кыскача татар тарихы** / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2011. – 68 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 7 нче китап).

Моңарчы фән даирәсендә билгесез булып килгән бу хезмәттә Борынгы Болгар, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәверләрендәге вакыйгалар тасвирланган.

Хезмәтнең язылган вакыты 1860 нчы еллар, ә авторы – Хөсәен Фәезханов булган дип исәпләнә.

**Сәяхәтнамәләр** / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2011. – 84 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 8 нче китап).

Бу җыентыкта дүрт сәяхәтнамә: татар сугышчысының 1756 елгы язмасы, 1937–1938 елларга караган Кырым сәяхәтнамәсе, 1945 һәм 1953 еллардагы хаҗ сәфәрләрен тасвирлаган текстлар туплап бирелде.

**Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте** / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2012. – 184 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 9 нчы китап).

Китапта XX гасырның беренче яртысында Кытайдагы Шанхай шәһәрендә яшәгән татар мөһаҗирләренең тормышы тасвирлана. Андагы төрки-татарлар 1925 елдан башлап оештырылган төрле җәмгыятьләре ярдәмендә милли-мәдәни мохитне 1940 нчы еллар ахырына кадәр саклап килгәннәр.

Бу җыентыкта Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсе-

нең 1934–1936 еллардагы җыелыш беркетмәләре һәм шушы оешма эшчәнлеген яктырткан, мөһаҗирлек матбугатында дөнья күргән материаллар урын алды.

**Кыз хикәяте** / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2012. – 184 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 10 нчы китап).

Китапта борынгы мавыктыргыч сюжетка татар телендә иҗат ителгән шигъри кыйссаның Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязма күчермәсе нәшер ителде.

Авторы хәзергә тәгаен ачыкланып бетмәгән бу хикәятнең иҗат ителү вакыты якынча XV–XVI гасырлар дип билгеләнә. Тексты 696 шигъри юлны тәшкил итә торган «Кыз хикәяте» матбугатта беренче тапкыр басыла.

Бу басмада дөнья мәдәниятендә Турандот исеме белән мәшһүр булган, Шәрыкнең мең елдан артык тарихка ия сюжетына бәйле төрле телләрдәге һәм төрле дәверләрдәге әсәрләр турындагы махсус мәкалә дә урын алды.

**Сөрген хатлары** / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2013. – 103 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 11 нче китап).

Бу җыентыкта Себергә (Иркутск ягына) гаиләсе белән бергә сөрелгән татар мулласының 1904 елда Балыклы авылындагы (хәзерге Самара өлкәсенең Камышлы районында) туганнарына язган күләмле ике хаты басылды.

Хат авторы шәхси кичерешләре белән бергә, рус-япон сугышы дәһшәтләрен дә тасвирлаган. Хат текстлары сагышлы-моңлы һәм фәлсәфи эчтәлекле шигырьләр белән баетылган.

Сөргеннән җибәрелгән бу хатлар үз чорының эпистоляр жанры үрнәкләре буларак әһәмиятле.

**«Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр** / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2013. – 128 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 12 нче китап).

Шәһри Болгар һәм шәһри Казан – борынгы дәвер бабаларыбыздан алып хәзергәчә күңелләрнең иң түрендә саклана торган изге төшенчәләр. Болгар-Казан тарихларына караган бәет-мөнәҗәтләр инде күп чыккан һәм өйрәнелгән булса да, бу җыентыкта моңарчы файдаланылмаган чыганаклардан алынган вариантлар һәм кайберләре бөтенләй онытылган текстлар урын алды.

«Сөембикә бәете» дип танылган әсәрнең төп чыганагы төгәл ачыкланып, бу китапка аның да тулы тексты кертелде.

## Книги, изданные в серии «Татарская археография»

В 2008 году издательством «Милли китап» Национальной библиотеки Республики Татарстан начата публикация научно-популярных сборников из серии «Татар археографиясе» (Татарская археография). Основной целью серии является публикация текстов татарских литературных, исторических, документальных и других письменных памятников, хранящихся в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан.

В сборниках представлены тексты в переложении на современную татарскую графику и факсимиле рукописей, а также научные статьи, археографические описания рукописей, комментарии и резюме на русском языке. Все издания составлены Р.Ф.Мардановым.

**Первый сборник** содержит тексты двух поэм татарского поэта XVII века Мавля Кулый, которые известны пока в единственном списке 1754 года. Это – «Свойство сплочённых» и «Свойство желающих честно заработать богатство».

**Вторая книга** является публикацией текста древнетатарского эпического произведения (дастан) «Туляк китабы», сохранившегося в рукописном сборнике второй четверти XIX века.

**Третье издание** представляет собой описание 33 рукописей поэмы Кул Гали «Кысса-и Йусуф» (Сказание о Йусуфе), хранящихся в Национальной библиотеке Республики Татарстан.

**В четвертой книге** опубликованы два варианта текста поэмы

«Нур-и судур» (Свет сердец) татарского поэта XVI века Мухаммедьяра, хранящиеся в Национальной библиотеке Республики Татарстан. Списки, один из которых состоит из 1165 стихотворных строк, а другой содержит 1023 строки, относятся XVIII веку.

В публикуемых текстах указаны все текстологические особенности, отличающие их от критического текста поэмы, изданного в 1997 году.

**Пятая книга** представляет собой сборник статей об археографических изысканиях и исследованиях, проведённых сотрудниками Национальной библиотеки Республики Татарстан. Статьи отражают результаты археографических экспедиций, проведённых в городах и сёлах Республики Татарстан, Республики Башкортостан, Удмуртии, а также в Горьковской, Кировской, Самарской и Свердловской областях. Одна из статей посвящена итогам археографической экспедиции Казанского государственного университета 1986–1992 годов, участником которых являлся сам автор.

**В шестой книге** серии представлен текст поэмы «Кысса-и Мансур» (Сказание о Мансуре), посвящённой известному в мусульманской истории Мансуру аль-Халладжу (858–922), казнённому за суфийские взгляды. Публикуемый поэтический текст ранее не был известен науке. В Национальной библиотеке Республики Татарстан хранятся два неполных, но взаимодополняющих списка XVIII века этого литературного памятника. Установлено, что текст Сказания о Мансуре состоит из 867 бейтов, то есть двустиший.

**Седьмая книга** представляет собой публикацию текста ранее неизвестного сочинения по истории татарского народа. Научное значение данного сочинения состоит в том, что оно является одним из первых подобного рода исторических трудов, написанных татарскими учёными. Текст рукописи содержит краткие сведения об исторических событиях времён Булгарского государства, Золотой Орды и Казанского ханства, основанные на русских и татарских источниках. В связи с утратой последних листов тетради, «история» прерывается на времени правления хана Халиля (1463–1467).

В самой рукописи автор и год не указаны. В результате текстологического изучения было установлено, что его автором является известный татарский востоковед, историк, лингвист, педагог и каллиграф Хусаин Фаизханов. Время создания текста датируется 1859–1860 годами.

**Восьмая книга** является сборником, в которой опубликованы тексты четырёх путевых записок, хранящихся в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан.

Первая из них – рукопись военнослужащего татарина, где описан маршрут похода 1756 года, начавшегося из местности около города Уфы до нынешней территории Черниговской области Украины. Участники похода направлялись в Семилетнюю войну.

Автором второго текста является Губайдулла Рахматуллин, уроженец нынешнего Кукморского района Республики Татарстан. Он, находясь в 1937–1938 годах в Крыму, описал много интересных фактов, относящихся хозяйственной и социально-политической жизни Крыма.

Путевые записки 1945 и 1953 годов представляют собой путешествия мусульманских паломников из Советского Союза в Саудовскую Аравию, под руководством муфтиев Габдрахмана Расули (1881–1950) и Шакира Хаялетдинова (1890–1974).

**Девятая книга** посвящена национально-культурной жизни тюрко-татарских эмигрантов, проживавших в 1920–1940-ых годах в городе Шанхае.

Основную часть данного сборника составляют впервые публикуемые тексты протоколов собраний правления Общества культуры тюрко-татар города Шанхая 1934–1936 гг. Данный документальный источник – журнал протоколов – был передан в 1993 году Равилем Салиахметом, проживающим в США, бывшему директору Национальной библиотеки Республики Татарстан Р.И.Валееву.

**Десятая книга** представляет собой публикацию текста поэмы «Кыз хикаяте» (Сказание о девушке). Сказание основано на древне-

восточный сюжет о мудрой деве, которая имеет всемирную известность под названием «Турандот».

Рукописный сборник, содержащий полный текст «Кыз хикаяте» и относящийся к последней четверти XVIII века хранится в Национальной библиотеке Республики Татарстан.

«Сказание о девушке» состоит из 348 бейтов-двустиший. Это сказание написано неизвестным автором в форме «назира» на поэтическое произведение, созданное поэтом золотоордынского периода Ибрахимом в 1382 году.

Автор и дата поэмы «Кыз хикаяте» в самом тексте не указаны. Крайние границы времени создания этого сказания можно определить началом XV – серединой XVI веков. Автором, предположительно, мог быть татарский поэт Мухаммедьяр, живший в первой половине XVI века. На это указывают сходство идей, а также стиль поэтического изложения и языковых особенностей известных произведений этого автора и поэмы «Кыз хикаяте».

**В одиннадцатом выпуске** опубликованы оригинальные памятники эпистолярного жанра – два письма татарского муллы Шайхутдина, сосланного вместе с женой и сыном в Сибирь. Вместе с ними ссылку отбывали его земляки (родственники и односельчане с семьями).

Письма были написаны в 1904 году и отправлены из поселения близ городов Иркутска и Усолье-Сибирское в адрес родственников – в деревню Балыклы (сегодня Камышлинский район Самарской области).

Письма Шайхутдина полны тоски по родной земле и по близким людям. В обоих письмах автор упоминает русско-японскую войну, которая шла в то время.

В текстах писем содержатся и поэтические строки. Второе письмо особенно изобилует стихами – почти все поля страниц исписаны стихотворениями разного содержания: от простых назидательных куплетов до философски утончённых.

**В двенадцатом выпуске** серии опубликованы образцы татарского народного творчества – баиты. Представленные тексты (пол-

ные и их фрагменты) посвящены историческому прошлому татарского народа и историческим событиям Булгарского государства, Золотой Орды и Казанского ханства.

В данном сборнике представлены тексты нескольких баитов, посвящённых древнему Булгару. В произведениях Булгар воспевается как священный центр принятия Ислама, что соответствует действительности. Как известно, Волжская Булгария официально приняла Ислам в 922 году. В баитах упоминаются имена булгарских святых, а также некоторые историко-географические названия древнего города. Сочинения пронизаны скорбью по славному прошлому, в них выражена сокровенная мечта посетить эти знаменитые святыни Поволжья. Строки в одном из текстов баита – «жемчужный и яхонтовый Булгар» – символизируют его значимость в духовной жизни народа.

В книге представлены тексты баитов из неиспользованных раньше письменных источников, хранящихся в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан, также в фонде №18369 Национального музея Республики Татарстан. В результате сравнения этих текстов с ранее опубликованными вариантами были выявлены некоторые различия. Несколько баитов опубликованы впервые.

# ЭЧТӘЛЕК

«Сугышта вәйран була газиз башлар...» ................................ 3

Мөнәҗәт: Сугыш әхваленнән ................................................ 41

Мәдхе ән-нәби саллаллаһу галәйһи вәссәлам .................... 53

Ятимнәр бәете................................................................ 57

Плиннәрнең бәете .......................................................... 69

Кулъязманың тасвирламасы ................................................ 90

Сүзлек............................................................................ 99

Резюме.......................................................................... 106

«Татар археографиясе» сериясендә
чыккан китаплар......................................................... 109

Книги, изданные в серии
«Татарская археография» ......................................... 114

**БАИТЫ ПЕРИОДА ПЕРВОЙ МИРОВОЙ ВОЙНЫ**
(на татарском языке)

Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Ильдар Габидуллин
Корректор: Миляуша Шакирова

Басарга кул куелды 16. 04. 2014. Форматы 60х84 1/16.
Тиражы 300 данә. Заказ № 319.
Татарстан Республикасының Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33.

Подписано к печати 16. 04. 2014. Формат 60х84 1/16.
Тираж 300 экз. Заказ № 319.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.